АВЫЛГА КАРАП

Алкоголь инспекциясе хәмер сатуны арттыруны сорый

> 5

АЗАТ ФАЗЛЫЕВ:

«Иң ышанган кешем – Алсу»

> 12

БЕЗНЕКЕЛӘР – ОЛИМПИАДАДА

Пекиннан Татарстанга кемнәр медаль белән кайтыр?

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 16 (28789) | Җомга | 4 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖЫЛЫТУ

БЕЛГЕЧЛӘР, ТАТАРСТАНДА УРТАЧА һАВА ТЕМПЕРАТУРАСЫ КҮТӘРЕЛӘ, ДИ

Якын киләчәктә кышкы зәмһәрир суыкларны бөтенләй сагынып искә алырга туры килмәгәе. Ник дигәндә, кыш елдан-ел җылырак килә. Белгечләр моны глобаль җылыну нәтиҗәсе дип саный. Балтач районының Янгул авылында яшәүче «халык синоптигы» Әмир Шәрәфиев исә быелгы кышның соңгы аен болай фаразлый: «Бөтен суык язга калачак!»

> 17

Ишетми калмагыз

Ашыгу ярамый

Казанда Җәмигъ мәчете төзелешенә нигез ташы салу Болгарда ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган чаралар исемлегенә кертелгән. Яңа мәчет урыны шушы вакытка билгеле булачак. Әлегә берничә урын карала. Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова әйтүенчә, тәгаен карар шәһәр төзелеше, экологик экспертизалардан соң гына кабул ителәчәк. Моның өчен вакыт кирәк. «Президент өчен иң мөһиме – төзелеш урынын тиз генә билгеләп кую түгел, ә барлык фикерләрне җентекләп өйрәнеп, мәчет өчен иң уңайлы урынны сайлап алу», – дип искәртте Лилия Галимова.

Акчаны кайтарып булачак

Үзәк банк мошенниклар урлаган акчаны кешеләргә кире кайтарырга тәкъдим итә. Бу хакта «РИА Новости» яза. Ләкин бер шарты бар: кредит оешмасы Үзәк банк киңәшләрен үтәмәгән очракта гына акча хуҗасына кайтарылырга тиеш. Инде узган елда ук бу җәһәттән тәкъдимнәр әзерли башлаганнар. Үзәк банк мошенниклардан зыян күрүчеләргә урланган акчаның 80–90 процентын кайтаруны күздә тота. Әмма клиент акчасының счеттан алынуы турында банктан смс килгәннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

Ипотека алучылар арта

1 гыйнварга Татарстанда яшәүчеләргә бирелгән торак ипотекасының гомуми күләме 347,6 миллиард сум тәшкил иткән. Бу сан 2021 ел башыннан 28,3 процентка күбрәк. Үзәк банкның Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Марат Шәрифуллин әйтүенчә, республика халкы ипотекадан актив файдалана. Бер ел эчендә барлыгы 68 меңгә якын ипотека кредиты (2020 елдагыга караганда 5,5 процентка күбрәк) алынган. Узган елда ипотека буенча 176,3 миллиард сумнан артыграк акча бирелгән (еллык үсеш – 25,4 процент). Вакытында түләнмәгән кредит бурычы 0,4 процентны тәшкил иткән.

Районнарда ни хәлләр?

Әгерҗе

Яңа уку елында Әгерҗедә ТИСБИ көллияте вәкиллеген ачарга ниятлиләр. Уку йортында мәгълүмат системалары һәм программалаштыру, логистика буенча операция эшчәнлеге, туризм юнәлешләре буенча белем бирергә җыеналар. Чит шәһәрләрдән килгән студентлар өчен аларның Түбән Кама агросәнәгать көллиятенең Әгерҗе филиалы тулай торагында яшәү мөмкинлеге карала.
(«Әгерҗе хәбәрләре»)

Чирмешән

Район үзәгендә әниләргә һәйкәл ясау идеясе ун еллар элек барлыкка килгән. Аны Кара Чишмә авылыннан Саимә апа Моратова күтәреп чыкты. Бу фикерне халык та хуплады. «Ана һәйкәле өчен эскиз-проект әзер, аны Муса Вилданов ясады. Һәйкәл булачак урынны да сайладык, аны өлкәннәр һәм инвалидлар йорт-интернаты янында төзергә җыенабыз. Һәйкәл төзүгә смета ясала. Аннан соң бу эшкә иганәчеләр табасы кала», – диде район башкарма комитеты җитәкчесе Илфат Шәйдуллин.
(«Безнең Чирмешән»)

Кукмара

Районда ике мәктәп төзекләндереләчәк. Бу хакта үзенең Instagram сәхифәсендә район башлыгы Сергей Димитриев хәбәр итте. Ремонт эшләрен Кукмараның өченче һәм Нырья урта мәктәпләрендә үткәрү планлаштырыла. «Бүлеп бирелгән акчага мәктәпләрнең фасадларын ремонтлау, кабинетларны төзекләндерү, Нырья мәктәбендә түбәне яңарту планлаштырыла. Өченче мәктәп территориясендә алга таба яңа корпус төзеләчәк. Төзекләндерү эшләре заманча стандартларга туры китереп башкарылачак, белем йортларында белем-тәрбия бирү өчен яхшы шартлар тудырылачак», – диелә хәбәрдә.
(«Хезмәт даны»)

Түбән Кама

Авылларда халык җыеннары, эпидемиологик хәл кискен булу сәбәпле, онлайн режимда үткәрелә. Кызыл Чапчак авыл җирлеге трансляциясенә 100дән артык кеше кушылды. Ачыктан-ачык сөйләшү барышында авыл җирлеге башлыгының узган елгы эш йомгаклары турында чыгышы тыңланды, быелга бурыч-максатлар билгеләнде. Авыл халкы видеоэлемтә аша төрле структура җитәкчеләренә үз сорауларын бирде, тәкъдимнәрен кертте. Очрашу барышында медицина, ТКХ, мәгариф, газ кертүгә кагылышлы сораулар яңгырады. Шәңгәлче халкы да онлайн форматта агымдагы елга өстенлекле бурычларны билгеләде, алар арасында үзара салым җыюны активлаштыру, дәүләт һәм республика программаларында катнашу, юлларны төзекләндерү эшен дәвам итү, урамнарны яктырту кебек мәсьәләләр күтәрелде.
(e-nkama.ru)

ЧИСТА ИТЕП ЭШЛИСЕ

Татарстанда экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләренә һәрвакыт аерым игътибар бирелде. Президент Рөстәм Миңнеханов Росприроднадзорның Идел-Кама Төбәкара идарәсе киңәшмәсендә шулай дип белдерде.

tatarstan.ru

Киңәшмә алдыннан Идел-Кама Төбәкара идарәсе бүлегенең һәм Татарстан буенча лаборатор анализ һәм техник үлчәү үзәге филиалының яңа бинасын ачу тантанасы узды. Заманча җиһазландырылган лаборатория атмосфера һавасын, агып чыгучы суларны, туфракны, җитештерү һәм куллану калдыкларын тикшереп торырга, алдан чарасын күрергә мөмкинлек бирачәк. Шулай ук Росприроднадзор хезмәткәрләренә 10 яңа автомобиль тапшырдылар.

Рөстәм Миңнеханов киңәшмәдә илкүләм проектлар кысаларында экологияне саклау буенча киң колачлы дәүләт программалары эшләнгәнен искә төшерде. «Экологиягә моңарчы бу кадәр акча бүлеп бирелмәде. Бүген безгә, барлык мөмкинлекләрдән файдаланып, нәтиҗәле эшләргә кирәк. Бу мәсьәләдә әйләнә-тирә мохиткә зур йогынты ясаган предприятиеләр дә җаваплы булырга тиеш. Республика бюджетыннан су сыйфаты һәм чистарту корылмалары өчен тотыласы акча күләмен шактый арттырдык инде», – диде Татарстан Президенты.

Утырышның Түбән Камада узуы очраклы түгел. «Танеко»да, «Түбән Кама нефть химиясе»ндә зур проектлар тормышка ашырыла, яңа проектлар сафка баса. Әйтик, киңәшмә алдыннан Президент «Түбән Кама нефть химиясе» мәйданчыгында ЭП-600 яңа олефин комплексын төзү эшләре белән танышты. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, җитештерү үсеше белән уңайлы яшәү мохитен саклау арасында уртаклыкны саклау мөһим. «Экология мәсьәләләре – тормыш сыйфатының нигезе. Безнең җәмәгать киңлекләрен, ишегалларын төзекләндерүгә зур акча тотабыз. Әмма сыйфатлы һава, яхшы су булмаса, берни дә эшләп булмый», – диде республика башлыгы.

Президент утырышта еллар буе хәл ителмәгән проблемалар барлыгын әйтте. Әйтик, ләм кырларыннан котылу өчен федераль ярдәм кирәк. Чулман елгасын чистарту өчен «Чиста Идел»гә охшаш программага өмет итәләр. Шул ук вакытта кешенең табигатькә мөнәсәбәтен дә үзгәртәсе бар. «Балаларда кечкенәдән үк экологиягә, әйләнә-тирә мохитне саклауга җаваплы караш тәрбияләргә кирәк. Безнең «мәктәп патруле» бар, әлеге проектны һичшиксез дәвам итәчәкбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент билгеләп үткәнчә, табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек тә зур әһәмияткә ия. Сәнәгать үсеше нык шартларда бигрәк тә. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан алга таба да Росприроднадзор белән хезмәттәшлекне үстерәчәк. «Татарстанның үз халкы турында ни дәрәҗәдә кайгыртуын күрәбез. Ә халыкның тормыш сыйфатын күтәрү – төп максатыбыз», – диде Светлана Радионова.

Депутатлар 10 февральдә җыела

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышы 10 февральдә узачак. Дәүләт Советы Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина әйтүенчә, «Гаммави хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законга төзәтмәләрне карау төп мәсьәләләрнең берсенә әйләнәчәк. Парламент Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов җитәкчелегендә эш төркеме федераль закон проектына төзәтмәләр әзерләгән. Дәүләт Советы депутатлары кабул иткән очракта, алар Думага җибәреләчәк.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстаннан барлыгы 29 төзәтмә әзерләнелүен билгеләп үтте. «Президент Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы депутатлары белән очрашып, закон проекты буенча кулай чишелешләр табуга кызыксыну күрсәтте, – диде ул. – Без шулай ук бу юнәлештә башка төбәкләр парламентлары белән хезмәттәшлекне дәвам итәбез». Ул төзәтмәләрнең бер өлешен, закон проектын икенче укылышта караганда, Татарстаннан сайланган Дума депутатлары кертәчәген әйтте.

Депутатлар киләсе утырышта республиканың 3 закон проектын (җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота) беренче укылышта карап тикшерергә җыена. Моннан тыш утырышның көн тәртибенә Татарстанда Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең 2021 елдагы эшчәнлеге турында чыгышы кертелгән. «Парламент сәгате» кысасында республикада дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру мәсьәләсе каралачак.

Бюджет, салым һәм финанс комитеты «Татарстан Хисап палатасына поручение турында» Дәүләт Советы карары проектын әзерләгән. Палатага 2019–2021 елларда урта һөнәри белем бирү өлкәсенә, шулай ук мөшгульлек өлкәсенә (инвалидларны эшкә урнаштыруны оештыру чараларын кертеп) бирелгән бюджет акчасыннан ничек файдаланылганлыгын тикшерүне йөкләү тәкъдим ителә.

Моннан тыш парламентчылар 11 федераль закон проектын караячак.

ТАТАРСТАНДА ПАРЛАМЕНТ ДӘРЕСЛӘРЕ БАШЛАНА

Дәүләт Советында тарих, җәмгыять белеме һәм хокук укытучылары, депутатлар өчен семинар узды. Анда «Мин – гражданин! Минем хокукларым һәм бурычларым» дигән 2022 елгы парламент дәресләренә старт бирелде.

Парламент дәресе – Дәүләт Советының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәгарифне үстерү институты белән уртак проекты. Быел инде ул республиканың барлык мәктәпләрендә ундүртенче тапкыр үткәреләчәк. «Уночь ел эчендә бу проект депутатларның укучылар белән хезмәттәшлеге өчен бик әйбәт мәйданчыкка әйләнде, – диде Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, семинарда катнашучыларга мөрәҗәгать итеп. – Дәресләр һәр ел саен уңай яктан бәяләнә. Димәк, «укытучы – укучы – депутат» форматында аралашуга, чыннан да, ихтыяҗ бар дигән сүз».

Быел парламент дәресенең темасы Россия гражданнарының хокуклары һәм бурычлары турында булачак һәм ул Татарстан Республикасы Конституциясенең 30 еллыгына багышланган. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Конституция, һичшиксез, гражданлык хокукларының һәм ирекләренең ышанычлы гарантиясе булып хезмәт итә. Парламент башлыгы фикеренчә, Төп Закон – вакытлар узу белән төрле социаль-сәяси факторлар йогынтысында үзгәрергә мөмкин булган «тере документ».

Парламент дәресләре февраль – март айларында узачак, аның кысасында 1 февральдән 31 мартка кадәр укучылар арасында иҗади бәйгеләр булачак. Быел беренче тапкыр социаль челтәрләрдә парламент дәресе турында иң яхшы медиаконтентка конкурс үткәрелә. Бәйгегә нәтиҗәләр апрельдә, Россия парламентаризмы көне алдыннан ясалачак, җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы парламентта узачак.

КАРАШ БАШКА, ЭШ – ШУЛ УК

Нәтиҗә

Мәгълүмат ташкыны чорында халык бөртектән кибәкне ничек аера? Кайсы матбугат чарасына күбрәк ышана? «Татмедиа» агентлыгының йомгаклау коллегиясе утырышында узган елга нәтиҗә ясадылар.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

– Пандемия безне үзгәртте, әмма тормышка, һөнәребезгә булган мөнәсәбәтне үзгәртә алмады. Бер-беребезне кадерли башладык. Вакыйгалар үзәгендә, гел беренче булу теләге кимемәде. Хәтта пандемия дә республиканың актив, вакыйгаларга бай тормышын киметә алмады, – дип башлап җибәрде үз чыгышын «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев.

Күп нәрсәләр үзгәрсә дә, укымышлылыгыбыз үзгәрмәгән. Айдар Сәлимгәрәев әйтүенчә, Татарстан әле дә матбугат белән тәэмин ителеш буенча Россия төбәкләре арасында алдынгы урында тора. Роскомнадзорның бездәге идарәсе мәгълүматлары да моңа дәлил: республикада 725 массакүләм мәгълүмат чарасы эшләп килә. Шуларның 390ы – газета-журналлар, 180 радиоканал һәм программалар, 80 электрон басма, 68 телеканал, 7 мәгълүмат агентлыгы. Республикада 1 мең кешегә 213 данә вакытлы матбугат туры килә. Чагыштыру өчен: ил күләмендә бу күрсәткеч 74 кенә.

Җитәкче «Татмедиа» базасында эшләп килүче күп кенә онлайн проектларның уңышка ирешүләрен дә билгеләп үтте. Шулар бәрабәренә социаль челтәрләрдән файдаланучылар санын да арттырганнар. Замана үз таләпләрен куя инде ул: интернет киңлекләрен сыйфатлы медиапродукт (бигрәк тә татар телендә!) белән тәэмин итү ихтыяҗы елдан-ел кискенрәк килеп баса. Бу юнәлештә эш дәвам итәчәк.

Сүз уңаеннан, Цифрлаштыру елына аяк басуыбызны исәпкә алып, коллегиядә Татарстанда барлык теле- һәм радиоканалларның бердәм цифрлы платформасы барлыкка киләчәген хәбәр иттеләр. Моңа өстәп, «Дәүләт секторында цифрлы коммуникацияләр: киләчәк бурычлары» бөтенроссия форумын оештыру күздә тотыла. Шулай ук газета-журналларның цифрлы архивын булдырырга исәп. Бу басма мәгълүмат чарасының гомерен дә озынайтачак: электрон киңлектә кәгазь саргаймый, тузмый бит!

Онлайн сүзен күп куллана башласак та, традицион мәгълүмат чарасы саналган төбәк телевидениесе интернеттан икеләтә алдарак бара икән. Сораштырулардан күренгәнчә, кешеләрнең 80 проценты телетапшырулар белән дус. Хәбәри интернет-ресурсларга сораштыруда катнашучыларның 45 проценты гына мөрәҗәгать итә, ди. Шул ук вакытта 84 проценты интернетны күңел ачу яисә белешмә мәгълүмат эзләү максатыннан куллануын әйткән.

Утырышта җитешсезлекләргә дә тукталдылар. Алары исә яңалык түгел. Хат ташучылар җитмәү – басма матбугатның баш бәласе. Сораштырулар күрсәткәнчә, Лаеш, Мамадыш, Кайбыч, Яңа Чишмә, Менделеевск, Питрәч районнарында почтальоннар җитми, ә Минзәләдә дистәләгән авылга бер почтальон хезмәт күрсәтә. Әтнә, Бөгелмә, Биектау, Лениногорск, Ютазы, Тукай районнарында кайбер почта бүлекләре бөтенләй эшләми – ябылган. Кама Тамагында алты зур торак пунктта элемтә бүлекләре юк инде.

Кадрлар кытлыгы да проблема. Айдар Сәлимгәрәев чыгышыннан аңлашылганча, медиа юнәлеше буенча белем алганнарның яртысыннан азрагы гына үз белгечлеге буенча эшкә урнаша. Тармак 5 төрле белгечкә мохтаҗ: корреспондент, режиссер, SMM-белгеч, реклама буенча белгеч, мөхәррир.

Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, тармак эшенә гомуми бәя биреп, журналистларга аудиторияне саклап калуга бәйле киңәшен дә бирде.

– Журналистларга мәгълүматны укучыларга һәм тамашачыларга халыкка уңайлы каналлар аша тапшыру мөһим. Мәгълүмат тиз тарала. Бу шартларда журналистларның җаваплылыгы да арта. Мәгълүматны тикшерергә кирәк. Игътибарсызлык хатасы кыйммәткә төшәргә – ялган хәбәрләр таралырга һәм кемнеңдер мәнфәгатьләренә зыян китерергә мөмкин, – диде ул.

Коллегиядә массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә дәүләт бүләкләре дә тапшырылды. Хезмәттәшебез – корректор Илүсә Миңнаҗевага Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәте белдерелде.

Йортка хуҗа булсаң, газ кирә

Быел Татарстанда 8534 йортка бушлай газ кертәчәкләр. Былтыр аны 687 хуҗалыкка тоташтырганнар. Билгеле булганча, Россия Президенты Владимир Путин күрсәтмәсе нигезендә, илдә социаль газлаштыру программасы тормышка ашырыла. Капка төбенә кадәр газны бушлай сузалар. Өйгә керткән өчен үзеңә түлисе.

– Кулында йортка һәм җиргә документы булган һәр кешегә газ киләчәк. Кайберләренә тизрәк тә булыр, ә инде газ кертү өчен техник мөмкинлекләр булмаган очракта, газчылар вакытны билгеләргә тиеш була. Безнең максат бер – газ кертергә гариза биргән һәр кешенең теләге үтәләчәк, – диде журналистлар белән очрашуда «Газпромтрансгаз Казан» оешмасы генераль директорының җитештерү буенча урынбасары Михаил Фролов.

«ГазпромтрансгазКазан» оешмасы халыктан газ кертү өчен гаризалар җыюын дәвам итә. Быелның 28 гыйнварына 9 581 гариза кабул ителгән. Бу эшләр өчен 4 млрд сумга якын акча тотылачак.

Михаил Фролов гаризаны ничек язасын да аңлатып үтте. Бер кеше документны берничә юл белән тапшырса да, ул бер генә тапкыр теркәләчәк. Буталчыклар булмаячак, дип ышандырды урынбасар.

– Гаризаны кәгазьдә тутырып, горгаз, райгаз оешмаларына тапшырырга да, «Дәүләт хезмәтләре» порталында да теркәргә мөмкин. Гаризада паспорт, СНИЛС мәгълүматларын, телефон номерын күрсәтергә, йортка һәм җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәсен кушымта итеп бирергә кирәк, – ди ул.

Газлаштыру программасына ничек эләгергә соң? Бер шарт бар – кешенең җиргә рәсми рәвештә хокукы булырга тиеш. Газны өй җылыту һәм ризык әзерләү максатыннан кертү шарт. Тагын бер кат исегезгә төшерәбез: газны өйгә кадәр кертү өчен акча түләргә туры киләчәк. Кайбер әүләр газ кертү һәм кирәкле җиһазлар алу өчен субсидиягә өметләнә ала. Аның күләме 80 мең сумга җитәргә мөмкин. Бөек Ватан сугышы ветераннары, күпбалалы гаиләләр, инвалид сабый тәрбияләүчеләр, җан башына туры килгән керем 10 мең сумнан түбән булган кешеләргә бу сумманы тулысынча түлиләр. Җан башына кереме 10–19 мең сум булса, чыгымның 75 процентын каплыйлар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Татарстанда газлаштыру дәрәҗәсе **99,6** процентны тәшкил итә. Республикада **1,5** миллион фатир һәм йорт газга тоташтырылган. Ел саен **19** меңнән артык фатир һәм йортка газ кертелә.

Әллә күпкә, әллә бик озакка…

КАЗАН КРЕМЛЕ «ТАҖ»ЛЫ ВАЗГЫЯТЬНЕ ШӘРЕХЛӘДЕ

«Дистант» булырмы, балалар өчен планлы медицина ярдәме күрсәтелү туктатылмасмы, Хөкүмәт читтән торып эшләү турында ни уйлый? Казан Кремлендә Татарстандагы коронавируска бәйле вазгыятькә бәя бирделәр.

Хәер, хәлләр турында саннар үзе үк сөйли. Узган тәүлектә коронавирус белән чирләүчеләр саны 912гә җитте.

Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова әйтүенчә, күп кенә хезмәт коллективларында да хезмәткәрләр карантинда утырырга мәҗбүр. Аның каравы республика хөкүмәте «дистант»ка күчәргә җыенмый.

– Хөкүмәт элеккечә эшләвен дәвам итә. Билгеле, авыручылар бар. Алар өйләрендә дәвалану курсын узалар, тест тапшыргач, яңадан эшкә кайталар. Хөкүмәтнең читтән торып эшләүгә күчүе турында сүз юк, – диде ул. Лилия Галимова хакимият вәкилләре арасында чирләүчеләр күпме икәнен әйтеп тормады. Мондый статистика алып бармыйлар икән.

Мәктәп укучылары өчен дә «дистант» булмаячак. Хәер, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, республиканың 11 мәктәбе карантинга ябылган инде. Дүртесе – Лаешта, өчесе – Минзәләдә, икешәр мәктәп – Актаныш һәм Тәтеш районнарында. 371 мәктәптә сыйныфлар таратылган, өйгә җибәрелгән. 1 февральдә андый мәктәпләр саны 335 иде.

– Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, белем бирү процессын туктатмау мөһим. Балаларга белем алу мөмкинлеге тудырырга кирәк. Шуңа күрә мәктәп укучылары читтән торып укуга күчмәячәк, – диде бу җәһәттән Лилия Галимова. Хакимияттәгеләр фикеренчә, бала-чагаларның мәктәптә булуы күпкә куркынычсызрак. Ник дигәндә, алар дәресләргә керешер алдыннан «фильтр» аша уза, мәктәптә санитар кагыйдәләр үтәлә, балалар өйдән генә укысалар, урамда, сәүдә үзәкләрендә йөрергә вакыт табарлар иде.

Сүз уңаеннан, республикада балалар өчен коронавируска каршы «Спутник М» вакцинасын 502 кешегә ясаганнар. Тиздән прививканың яңа партиясе кайтырга тиеш. Моңа кадәр республикада 2 меңнән артык доза вакцина кайтартылган иде.

2 февральдә Татарстанда планлы медицина ярдәмен күрсәтү һәм диспансеризация үткәрүнең вакытлыча туктатылуы хакында билгеле булды. Бу балаларга, онкологик, кан әйләнеше, диабет кебек чирләре булганнарга, йөкле хатын-кызларга кагылмый. Казан Кремлендә бу яңалыкны да шәрехләделәр.

– Сүз дә юк, мөмкин кадәр тизрәк элеккеге режимга кайту бурычы тора, чөнки без моның мөһимлеген аңлыйбыз, – диде Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе.

Сүз уңаеннан, сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков, планлы медицина ярдәмен күрсәтү якынча 10–14 көнгә туктаlып торыр, дип белдергән.

Әйтеп кенә бактым

Һәвәслек

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Мәйдан» телевизион каналы һәвәскәр башкаручыларны «Нурлы сәхнә» сәхифәсендә тамашачы хозурына чыгара башлагач, күңелдә: «Үзешчән артистлар, сәнгать коллективлары бүген күпме икән?» – дигән сорау туды. Ни генә әйтсәң дә, зур сәхнәгә юл авыл, район, шәһәр мәдәният сарайлары һәм клублары сәхнәсеннән башлана.

Бу хакта сүз башлагач, бер дустым: «Үзешчәннәр бу заманда нигә кирәк ул? Татарда хәзер җырчылар болай да буа буарлык», – дигән иде. Сүз дә юк, күп алар бездә һәм башкару осталыгы буенча кайбер үзешчәннәр белән профессионаллар арасында аерма да артык сизелми. Кайбер сәхнә «йолдыз»ларының шоуменнарга әйләнүе дә хак. Бәлки, болары да кирәктер, зоопаркка кергән кешенең маймылны карамыйча чыгып китәсе килми бит ул. Заман белән бергә рухи кыйммәтләр дә, эстрада сәнгатенә дә үзгәрешләр кермичә калмас. Сүзем – башка нәрсә турында. Профессиональ сәнгатькә юл нәкъ менә үзешчәнлектән башлана, дип уйлыйм. Һәрхәлдә, элегрәк шулай иде. Беренче булып телгә килгән исемнәрне генә атыйк. Винера Ганиева әле мәктәптә укыганда ук «Саз» ансамбленә йөрде. Зәйнәб Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов «Иделкәем» ансамблендә җырладылар. Исемлекне үзегез дәвам иттерә аласыз. Кемнең нәрсәгә һәвәс икәнлеге асылда әнә шундый иҗат коллективларында ачылды.

Хәзер шәһәр һәм район мәдәният йортлары һәм сарайларында һәвәскәр коллективлар күзгә ырып салырлык кына калды бугай. Элек һәрберсендә хор, бию, уен кораллары ансамбльләре, халык театрлары булып, аларны махсус белемле белгечләр җитәкләде. Коллективларның күбесе «халыкның» исеменә лаек булды, төрле конкурсларда җиңеп, лауреат исеме алды. Мин боларны ни өчен язам? Беренчедән, халык талантларга бик бай ул, әмма кешегә сәләтен ачарга мөмкинлек юк. Икенчедән, үзешчән коллективлар шәһәрдә милли мохит тудыра иде, татар яшьләрен бер тирәгә туплый иде алар. Бу – милли сәясәтнең бер өлеше дип уйлыйм.

Һәр район иҗади отчет концертлары белән Казан тамашачысы алдында чыгыш ясады һәм шунысы кызык: үзешчәннәр концертына тамашачы ишелеп килә иде. Әле телевидениедән даими рәвештә «Халык талантлары» дигән тапшырулар барды. Бу районнар арасында көндәшлек тудырды һәм район җитәкчеләре генә түгел, колхоз председательләре дә ярыша-ярыша дигәндәй, үзләрендә үзешчән сәнгать коллективлары оештыра башладылар. Без кызык хәлгә дә юлыктык әле. Минем телевидениедә музыкаль тапшырулар редакциясе мөхәррире булып эшләгән чак. Беркөнне кайсыдыр районнан колхоз председателе шалтырата. «Бездә халык хоры бар, тыңлап китә алмассызмы?» – ди. Бардык. Без килешкә сәхнәгә хәтле бизәп куйганнар. Хорда җырлаучылар колхоз тектергән күлмәкләрдән сәхнәдә басып тора. Председательдән: «Хорда ничә кеше инде?» – дип сорыйм. «Утыз», – ди бу. «Ничә тавышка җырлыйлар?» Ул башта аптырап калды, аннан үзен тиз генә кулга алды да: «Утыз кеше булгач, утыз тавышка инде», – дип куйды. Көлүдән чак кына тыелып калдым, хуҗаны уңайсыз хәлгә куясы килмәде. Кулын кысып рәхмәт әйттем мин аңа. Ничек әйтмисең ди, сәнгатьтән шактый ерак булган, «хор» дигәннең «х» хәрефен дә белмәгән бу кеше үзешчән сәнгать өчен әнә ничек җан атып йөри бит!

Үзешчән сәнгать бик көчле иде бездә. Мөслимнең дүрт тавышка җырлаучы академик хоры, Актанышның «Агыйдел» җыр-бию ансамбле, Арчаның егетләр ансамбле, халык уен кораллары оркестры, Азнакайның тынлы музыка кораллары оркестры үзләре генә дә ни тора!

Күңелне борчыган тагын бер нәрсә бар: бүген кемнең акчасы бар – шул телевидение экранына чыга, радиодан җырлый. Бу хакта сүз кузгатмаган да булыр идем, тик... Бер районлдагы талантлы җырчы дустыма (исемен әйтеп тормыйм): «Нигәдер сине радиодан җырлатмый башладылар әле», – дигән идем, радиога биреп куйган акчасы беткән булган икән, әле күптән түгел генә тагын фәлән мең илтеп биргән. «Озакламый тыңларсың», – дип юатты үзе, әмма күңелдә юшкын калды.

Әйткәннәрем, бәлки, зур сөйләшүнең башы булыр дип тә өметләнәм әле. Халык иҗатын кайчак чишмә белән чагыштырабыз үзе, әмма чишмә ургып торсын өчен, аның юлын да ачып торырга кирәк бит әле, диясе килә.

ӘТТӘ ТҮГЕЛ ХИКМӘТ

Россиядә хәл ителми торган ике проблема бар: берсе – этләр талавы, икенчесе – мәктәп буллингы. Башта ук бер нәрсәне искәртеп куйыйк: проблема һаман бар икән, димәк, аны хәл итәргә тиешле кешеләргә профессиональлек җитми. Профессиональлекнең җитмәве исә җавапсызлык белән бәйле. Мәсьәлә хәл ителәсе урынга, киресенчә, хәлләр катлаулана бара икән, урындагы түрәләр һәм югарырак җитәкчелек моның өчен берничек тә җавап тотмый: административ җаваплылыкка да тартылмыйлар, матди югалтулар да кичермиләр, төрмә җәзасы кебек кискен чаралар хакында инде әйтеп тә тормыйк.

Бары зур фаҗига булганда гына (әйтик, кораб батып яисә янгын чыгып, күп кешеләр һәлак булса яисә, зур банк янып, миллионнар бөлсә) масштаблы тикшерү эшләре башлана, кемнәрдер кулга алына, тикшерү изоляторында интегә башлыйлар. Ә бит эшне ул дәрәҗәгә җиткермәс өчен, вакытында бераз гына селкенергә, кайбер инструкцияләрне үтәргә, «үгез үлсә – ит» дип яшәү принцибыннан баш тартырга гына кирәк.

Әйдәгез, буллинг – балаларның мәктәптә һәм интернет челтәрендә эзәрлекләнүләре темасын тагын бер тапкыр алып карыйк. Әле менә яңа гына Россия Президенты каршындагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Мария Львова-Белова балалар омбудсменнары съездында уку йортларында буллингның кискен рәвештә үсеше турында белдерде. Вәкаләтле вәкил аппаратына мөрәҗәгатьләрнең һәр дүртенчесе мәктәпләрдә эзәрлекләүләргә бәйле икән. Күз алдына китерегез: кеше Мәскәүдәге иң югары җитәкчелеккә кайчан мөрәҗәгать итә? Башка бер чарасы да калмагач һәм бөтен беркемнән дә ярдәм ала алмагач.

Буллинг проблемасы белән бу юлларның авторы үз балаларына мөнәсәбәтле рәвештә бер тапкыр очрашты. Шунда аның чыганагын, нигезен күрергә насыйп булды. Күп тапкырлар язганым бар: үзем эшләгән һәм балаларым укыган мәктәптә андый проблема юк иде, чөнки коллективта үзара кешелекле мөнәсәбәтләр өстенлек итте. Әмма үз улым белән кызымны кечкенә вакытта, бишенче-алтынчы классларда укыганда, бер тапкыр чит мәктәпкә илтеп тордым. Эш болайрак булды: балалар табибы миңа аларны бер айга шифаханәгә җибәреп торырга киңәш итте. Гаиләдә киңәшкәч, без балаларга бер ай чит атмосферада яшәп алу зыян итмәс, дигән фикергә килдек һәм тиешле барлык процедураларны үтеп, балаларны үзебездән берничә йөз километр ераклыктагы шифаханәгә илтеп тә кайттым.

Ләкин шифаханә дигәнебез интернат-мәктәп булып чыкты һәм анда балалар бер айга гына түгел, кимендә бер елга киләләр, имеш. Мәктәптә тәртип ягы бик нык аксаганлыктан, юньле әти-әни анда баласын илтми, шуңа күрә балалар коллективын авыр хәлдәге гаиләләрдән туплыйлар. Аның схемасы болайрак икән: район мәгариф бүлекләренә интернат-мәктәпкә фәләнчә бала җибәрергә дигән разнарядка килә дә, башкача булдыра алмагач, бик үк тәртип булмаган, ярым-йорты гаиләләрнең балаларын ихтыяри-мәҗбүри шунда озаталар. Мәктәп үзе, чынлап та, табигатьнең бик яхшы урынында урнашкан, сәламәтлекне ныгыту өчен менә дигән мөмкинлекләргә ия. Анда берникадәр вакыт тәрбияләнү һәм дәвалану саулык өчен файдалы булырга тиеш. Әмма кемдер идеяне башта ук тамырыннан корыткан да, анда тәртибе белән бик мактана алмый торган балалар туплана, күбесе шунда берничә ел рәттән «дәвалана» башлаган.

Улым, бер генә айга килдек дип, түзәргә һәм сабыр итәргә була. Кызым исә гаделсезлекне бик авыр кичерә, әмма кичереп кенә калмый, һәрвакыттагыча протест белдерә. Тәрбиячеләр алдына мәсьәләне кабыргасы белән куя: тәртип урнаштыруны таләп итә. Мобиль телефоннарның чыккан гына вакыты иде ул, балаларга читкә китәсе булгач сатып алып биргән телефонны тәрбиячеләр шунда ук алып куялар. Гомумән, баланың әти-әни белән контактына алар каршы, чөнки «йорттан чүп чыгу»ны теләмиләр. Мобиль элемтәгә кереп булмагач, әти стационар телефонга шалтыратып, хәлне белешә инде, билгеле. Кызым тәрбиячеләрнең әти-әнигә берни дә әйтмәскә дигән кисәтүләрен колакка да элми. Әти шунда ук телефонга тәрбиячене чакырта, иртәгә үк үзенең килеп җитәчәген әйтә, балаларның документларын әзерләргә куша. Тавыш чыгарып торудан файда юк икәнлеге аңлашыла, чөнки мәктәптәге хәлне үзгәртү өчен, андагы коллективны тулысынча алыштырырга кирәк булыр иде, бу исә мөмкин түгел. Мәктәпкә баргач, тәрбияче белән кыска гына сөйләшү булып ала. Тәрбияче – югары белемле педагог: «Балаларыгызны юкка алаcыз, аларга бары бер шундый тормышка ияләнергә кирәк булачак бит инде», – дигән дәлил белән каршы торып карый.

«Татар-информ»

Мәктәпләрдә буллинг дип сөйләшәбез икән, ул менә шул нигездә утыра: эт тормышын үзгәртеп булмый, аңа ияләнергә кирәк дип саныйлар аны уңай якка үзгәртергә тиешле иптәшләр. Мәскәүдәге Югары икътисад мәктәбенең Фәнни-тикшеренү университеты, барлык федераль округлардагы 8500 укытучыдан сорашканнан соң, әле 2021 ел ахырында гына шундый нәтиҗәгә килде: мөгаллимнәрнең 2 проценты буллингны берничек тә җиңеп булмый дип саный, 35 проценты хәлне өлешчә генә яхшыртырга мөмкин, ди; 36 проценты бөтенләй проблема күрми, бары тик 26 проценты гына үз мәктәпләрендә бу мәсьәләне хәл иткәннәрен әйтә. Ни өчен проблема үсмәсен ди инде: педагогларның 75 процентка якыны аны чишү өчен яраклы түгел.

Урамнардагы хуҗасыз этләр темасы да нәкъ шуңа охшаган бит: төен чишелми, ә ныграк төйнәлә генә. Җәмгыятьтә аны ничек хәл итәргә икәнен өзеп кенә әйтә алган беркем дә юк. Чишелешнең әллә ничә төрле юлы күрсәтелә, әмма берсе дә тормышка ашырылмый. Ә урамнарда этләр талап үтергән балалар һәм хәтта өлкәннәр саны арта бара. Байкал аръягы краенда җиде яшьлек кызны эт көтүе талагач, Федерация Советына шул төбәктән сайланган сенатор Сергей Михайлов «Ерткыч этләрне һәм аларны яклаучыларны урынында атып үтерергә!» дигән хисле тәкъдим белән дә чыгып карады. Әйдәгез, «этләрне үтерү – кешелексезлек» дигән сүзләр белән килешик. Ә ерткычлар өзгәләп ташлаган сабыйлар язмышына битараф булу нәрсә?

Этләргә приютлар төзергә акча җитми, диләр. Бөтен акча урам көчекләрен тотып стерильләштерүгә китә, имеш. Әмма бу эш белән шөгыльләнү өчен тендерларны намуссыз кешеләр ота икән. Стерильләштерелгән этнең муенына махсус тамга (бирка) тагыла. Этләрне тотып, приютка җыючы волонтерлар исә, этнең биркасы бар, әмма буаз; тамгалы, ләкин балалаган, диләр. Менә бит чишелми торган проблеманың очы кая барып тоташа! Акча үзләштерелгән – эш башкарылмаган. Без Сталинны тиран дип сүгәбез бит әле. Әмма кайбер принципиаль мәсьәләләрдә җаваплы иптәшләрне стенага терәп сөйләшү кирәк ул. СССРда нефть һәм газ сәнәгатенә җитәкчелек иткән Николай Байбаков дигән кеше бар иде. Менә шул Байбаковны, Гитлер гаскәрләре Кавказга ыргылганда, төбәктәге нефть скважиналарын юк итүне оештыру өчен, Сталин чакыртып ала. Немецларга бер тонна гына Кавказ нефте эләксә дә, атачакбыз, дип кисәтә. Скважиналарны вакытыннан алда да шартлатырга ярамый, соңга калсаң да үлем җәзасы яный. «Сез миңа сайлау мөмкинлеге калдырмадыгыз, иптәш Сталин», – дип кенә әйтә ала курыккан Байбаков. «Сайлау менә монда», – дип, бармагын чигәгә төртеп күрсәтә тиран юлбашчы. Байбаков әфәнде озак еллар СССР җитәкчелегендә эшләде әле, димәк, дөрес чишелешне таба алган. Югарыда тәфсилләнгән проблемаларның чишелеше күпкә ансатрак аларның, җаваплы иптәшләр алдына катгый таләп кую гына җитми. Урам этләре проблемасын да хәл итә алмаган ил үсешнең катлаулы проблемаларын ничек хәл итә алсын инде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

ХӘМЕРСЕЗ АВЫЛ

Соңгы елларда авылларда эчкечеләр саны кимегән. Халык белән сөйләшкәч, әнә шундый фикергә килдек. Тик авылларда хәмер сату кибетләрен арттыргач, бу проблема кабат баш калкытмасмы?

«Дуңгызсыз яшибез, аракысыз да булыр»

Узган атнада Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе елга йомгак ясады. Аның җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов сүзләре буенча, республикада 1194 торак пункт бар. Шул исәптән 100 кеше яши торган 214 авылда кибетләр юк. Ә 100 кешедән күбрәк яши торган 593 авылда аракы сатылмый. Җитәкче фикеренчә, кибетләрдә легаль аракы сатылмау «күләгәдә алкоголь сатучылар» өчен кулай. Алар моннан бик оста файдаланып, халыкка үз товарларын тәкъдим итә.

– Шуңа күрә республиканың Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Кулланучылар союзы һәм район җитәкчеләре белән берлектә мондый авылларда кибетләр ачу бурычын куябыз. Болар райпо системасының модульле павильоннары да, элеккеге кибет тә, яңа җиңел корылмалар да булырга мөмкин. «Татспиртпром» белән мондый кибетләргә республика продукциясен минималь бәядән кую һәм төрле акцияләр куллану турында килешенде, – диде Җәүдәт Әхмәтханов.

Җитәкченең әлеге чыгышы халык арасында шау-шу кузгатты һәм аларны ике төркемгә аерды. Бер төркем кеше татар авылларында аракы сатуны көчәйтүне (кертүне) халыкны эчкечелеккә чыгарырга омтылыш дип кабул итсә, икенчеләре, мөмкинлекләр һәркемгә тигез булырга тиеш, дигән фикерен җиткерде.

– Дуңгыз асрамасак та, яшибез бит әле. Аракысыз да шулай яши алыр идек. Ул зәхмәт авылларга бөтенләй кермәсә, бик әйбәт булыр иде, әлбәттә, – ди Актаныш районы Иске Айман җирлеге башлыгы Марсель Әхмәтханов.

Без сөйләшкән кешеләр арасында башка фикердә торучылар да бар.

– Моңа бер яклы гына карарга кирәкми. Кибеттә аракы сатылу ул әле бөтен кеше дә кырылып аракы чөмерә дигән сүз түгел, – ди Апас районында яшәүче Илһам Шәрипов. – Авылларда аракы сатарга кирәкми, дигән фикерне, гадәттә, кайчандыр авылдан чыгып китеп, шәһәрдә яшәүчеләр әйтә. Шәһәрдә адым саен хәмер сата торган кибетләр булганда, авыл агае аны каяндыр эзләп йөрергә тиешме? Шампан шәрабен алыр өчен дә район үзәгенә барырга кирәк дигән сүз бит бу. Ә эчү белән мавыккан кеше барыбер теләсә кайдан табып эчә инде ул зәхмәтне. Һәм нәрсә эчә бит әле?! Аның менә шунысы да бар.

Дәүләт алкоголь инспекциясе мәгълүматлары буенча, узган ел иң күп алкоголь продукциясе Питрәч һәм Лаеш районнарында сатылган. Ә менә Сарман һәм Яңа Чишмәдә исерткеч эчемлекләрне азрак кулланулары ачыкланган.

«Ватаным Татарстан»ның социаль челтәрләрендә калдырылган фикерләрдән күренгәнчә, кибеттә аракы сатылмау көмешкә кууга, суррогат аракы сатуга бер сәбәп булырга мөмкин.

«Кибеттә аракы сату кирәк дип уйлыйм, – дип язган Алмаз Миңнуллин исемле укучыбыз. – Эчкән кеше барыбер җаен табачак, шуңа күрә заводта ясалганын куллансалар, әйбәтрәк булыр. Безнең авылда кибет бар, аракы сатыла. Әмма аңа карап кына кешеләр эчкечелеккә чыкмаган. Чөнки элеккеге сәрхушләр үлеп бетте, яшьләр юк. Шуңа күрә эчүчелек кимегән төсле. Ләкин бу алай түгел. Шәһәрдә яшьләр бик нык эчә, шуның өстенә наркомания тамыр җәйде. Менә шунысы бигрәк аяныч».

Әлмәт районының Бишмунча авылында моннан берничә ел элек ялган аракы эчеп агуланучылар булган.

– Авылыбызда суррогат белән агуланып үлүчеләр булды, – ди шушы авылда яшәүче Лилия Купаева. – Дөрес, ул хәлләргә шактый вакыт узды инде. Мин үзем кибеттә аракы булу суррогатка, көмешкә сатуга урын калдырмый дип уйламыйм. Чөнки аларда, гадәттә, кибеттәгедән арзанрак бәядән сатыла. Аннан соң бу кешеләр алкогольне тәүлекнең теләсә кайсы вакытында саталар. Җитмәсә, «булдырган кеше эше» дип, шуның белән мактаналар да. Миңа калса, җаваплы кешеләр мондый сыйфатсыз алкогольне кемнәр сатуын беләләрдер. «Кулларыннан тота алмыйбыз, дәлилләр юк», – дип акланалар. Шулай да безнең авылда эчкечелек белән проблема зур, дип әйтә алмыйм. 40 яшькә җитмәгән өч-дүрт ир-ат бар.

«Бездә аракы сатылмый»

Актаныш районының Усы һәм Кәзкәй авылларында алкогольле эчемлекләр бөтенләй сатылмый. Шуңа да, җирлекләр арасында чыгарылган рейтинг буенча (туучылар, үлүчеләр, авыр гаиләләр, низаглар, җинаятьләр, янгыннар саны буенча) алар беренче урында тора. Кәзкәй авылында исерткеч эчемлекләр сатылмаганга якынча 3–4 ел тирәсе.

– Авылда аракы сатылмауны халык аңлап кабул итте, – ди җирлек башлыгы Камил Әхмәтгалиев. – Аңа карап, эчкечеләр гел юк дип әйтеп булмый. Урамда әшәкеләнеп йөрмәсәләр дә, хәмер белән мавыгучы берничә кеше бар. Гомумән, соңгы дүрт елда авылларда эчкечеләр кимеде. Аракы сатылмагач, тәртип урнашты. Ләкин, кунак килсә, аракы табу проблема түгел. Күрше авыллар якын урнашкан, шуннан барып алырга мөмкин.

Җирлек башлыгы әйтүенчә, авылда ялган аракы, көмешкә куу буенча кисәтү эшләре алып барылган.

– Мин бу вазыйфага билгеләнгәндә кибеттә аракы сатылмый иде инде. Белүемчә, моның берничә сәбәбе бар. Беренчесе – халык теләге, икенчесе – лицензиянең кыйммәт булуы. Авылларда аракы сатуны оештыручылар аның файдасы турында да уйлый торганнардыр.

Әлеге исемлектә өченче авыл да бар иде. Тик Иске Айман авылы халкы белән сөйләшкәч, биредә аракыны быелдан кабат сата башлаулары билгеле булды.

– Аракы бездә бер елга якын бөтенләй сатылмады. Ел башыннан бер кибет лицензия алды, – диде җирлек башлыгы Марсель Әхмәтханов. – Аңа карап кына «астан» исерткеч эчемлекләр сатучылар булмады. Чөнки Әнәк авылы бездән нибары бер чакрым ераклыкта гына урнашкан. Авылда эчкече бер-ике кеше бар. Алар шуннан кайтарта.

Баштагы вакытларда авылда хәмер сатуны ураза аенда туктатып торганнар. Аннан соң яңа кибет хуҗасы лицензия ала алмаган. Шул сәбәпле бер ел исерткеч эчемлекләр сатылмаган.

Әңгәмәдәшебез әйтүенчә, соңгы биш-алты елда авылларда эчкечеләр бик нык кимегән.

– Алар хәзер бөтенләй юк дип әйтеп була, чөнки эчү модада түгел. Кеше узыша-узыша дөнья көтә. Яшеренбатырын түгел, элек төрле чараларда җитәкчеләргә мул табыннар кора идек. Хәмере дә була торган иде. Хәзер андый күренеш бөтенләй бетте. Чөнки кеше бер-берсенннән үрнәк ала. Каты эчкәне дә тыелып, башкалардан кыенсына башлый. Мин бу хәлләрне берничә ел махсус күзәтәм. Аракы эчүчеләр чыннан да кимеде. Миңа калса, биш елдан соң авылда көн саен «кәеф күтәреп» йөрүчеләр бөтенләй калмас. Ләкин мин көчләп тыюга каршы. Чөнки тыелган җимеш татлырак була. Ул хәлне катлауландырачак кына, – ди Марсель Әхмәтханов.

Имамнар каршы

Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтхановның, авылларда аракы сатуны арттырырга кирәк, дигән фикерен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы да игътибарсыз калдырмады. Алар бу уңайдан актив рәвештә ризасызлык күрсәтүен хәбәр итте. Имамнарның эшчәнлеге авылларда исерткеч эчемлекләр сату урыннарын киметүгә юнәлдерелгән. «Моның өчен хәзрәтләр җирле хакимият, халык, эшмәкәрләр, авыл советлары белән сөйләшүләр алып бара. Имамнарның тырышлыгы белән Татарстандагы 16 районга караган 30дан артык авылда кибетләрдә исерткеч эчемлекләр бөтенләй сатылмый яисә изге рамазан ае вакытында туктатыла», – диелә мөрәҗәгатьтә.

Шул рәвешле, Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең карары республика мөселманнары Диния нәзарәте мөхтәсибәтләренең халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, хәмер эчүдән баш тартырга чакыру һәм авылларда исерткеч эчемлекләрне сату нокталарын ябу буенча тырышлыкларын юкка чыгарачак дип саный алар. Һәм Татарстандагы татар авылларын хәмер сатудан сакларга чакыра.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕЛГЕЧ ФИКЕРЕ

Республиканың наркологик диспансеры баш табиб урынбасары Илдар ТАҖЕТДИНОВ:

Соңгы елларда районнардан килгән авыручылар саны кимүгә таба бара. Ул якынча 10–15 процентны тәшкил итә. Бу авыру өчен кибеттә аракы сатылу-сатылмау мөһим түгел. Республикада тормыштан бөтенләй аерылган дөм караңгы бер генә авыл да юк. Кешеләр район үзәгенә йөреп торалар, бер-берсенә якын урнашкан авыллар бар, аннан соң атнага берничә тапкыр күчмә кибет килә, хәмер аларда да сатыла.

ТАБИБ – КОРОНАВИРУС ТУРЫНДА:

«ЧИШЕЛМӘГӘН ТАБЫШМАКЛАР КҮП ӘЛЕ»

Менә инде өченче ел коронавирус дигән сер йомгагын сүтәбез. Сорауларга җавапларны белгечләр, табиблар, галимнәр, туган-тумачалар, дус-ишләр, таныш-белешләр белән бергәләп эзлибез. Моңа карап кына алар кимеми, әлбәттә.

Казан дәүләт медицина академиясенең педиатрия һәм неонатология кафедрасы доценты, башкаланың 1 нче балалар хастаханәсе педиатрия бүлеге мөдире Илдус ЛОТФУЛЛИН белән кабат COVID-19 чире һәм аңа бәйле иң еш очрый торган сорауларны барладык, вазгыятьне бәяләдек.

:: Илдус Җәүдәтович, инде шул гомер коронавирус белән бергә яшибез. Чирнең чишеп булмастай табышмаклары, белгечләр аңлап бетермәгән үзенчәлекләре дә калмагандыр инде?

– Коронавирус пандемиясе кешелек тарихына авыр бер сынау булып кереп калачак, әлбәттә. Күп кешеләр сәламәтлеген югалтты, үлүчеләр саны арта, икътисади зыян да шактый. Шулай да, һәр эшнең уңай ягы бар. Коронавирус очрагында бу уңай як – медицина фәненең алга китүе. Соңгы ике елда коронавируска бәйле рәвештә медицинаның төрле тармакларына зур кертемнәр ясалды. Биш-алты ел элек микробиология, иммунология, фармакологиянең һәм башка фәннәрнең шундый зур адымнар белән алга китәсен күз алдына китерү дә авыр иде. Медицинадан ерак торган кеше өчен бу нинди дер күзгә күренә торган нәрсә булмаса да, берничә елдан без бу алгарышның нәтиҗәләрен күрәчәкбез әле.

Әмма фән ничек кенә алга китмәсен, коронавирус сер булып кала бирә. Соңгы яңалык – «омикрон» дигән штаммның килеп чыгуы. Аны алдан фаразлап та булмый иде, булдырмау да мөмкин түгел. Әле алда тагын әллә нинди сюрпризлар булу ихтимал. Коронавирусның эволюциясе нинди юл белән дәвам итәр? Яңа штаммнар нинди булыр? Пандемия бетәрме, әллә инде бу дулкыннар гел кабатланып торырмы? Табышмаклар күп әле.

:: Күпләр: «Бәлки авырып алу һәм табигый иммунитет булдыру ясалма вакцина биргән иммунитеттан яхшырак булыр», – дип тә уйлый. Бу уңайдан ни диярсез, Илдус Җәүдәтович? Инфекция кичергәннән соң һәм прививкадан соң барлыкка килгән иммунитетның нәтиҗәлелеген берәр ничек бәяләп буламы?

– Иммунитетны болай «чын», «ясалма» дип бүлү дөрес үк түгел. Авырудан соң да, вакцинадан соң да якынча алганда бер үк механизм белән формалаша ул иммунитет. Эш бит аның нинди юл белән түгел, ә нинди бәһа белән формалашуында. Иммунитетны авырып барлыкка китерү артык кыйммәткә төшә дип уйлыйм.

«Вакцина бит ул панацея түгел», – диләр. «Панацея» ул – борынгы грек мифларында очрый торган тылсымлы әйбер. Килешәм, вакцина – панацея түгел. Медицина ул – фән, ә фәндә тылсым була алмый!

«Ихтимал» дигән сүз бар. Вакцинация коронавирусны авыр кичерү ихтималын, хастаханәгә эләгү, ахыр чиктә үлем ихтималын киметә. Ләкин 100 процент гарантия бирми! Монда сүз статистика турында бара: күпмедер кешегә авырмаска булыша, күпмесенә – авыруны җиңел кичерергә. Кайберәүләр вакциналы килеш тә каты авырый. Сирәк очракларда гына вакцинадан зыян күрергә мөмкин. Аерым кешедә коронавирус та, вакцина да үзен төрлечә күрсәтә. Ләкин хисләр күзлегеннән түгел, фән күзлегеннән чыгып караганда, иммунитетны вакцина ярдәмендә булдыру авырып барлыкка китерүгә караганда күпкә куркынычсызрак. Вакцинологиянең төп кагыйдәсе бу: вакцина инфекциянең үзеннән күпкә җиңелрәк, күпкә куркынычсызрак булырга тиеш. Шул вакытта гына аны кулланырга ярый.

:: Ревакцинация (кабат вакцина ясату. – Ред.) хакында күп сөйлибез. Ни өчен ул шул дәрәҗәдә мөһим? Һәм ни өчен кешеләр икенчесен ясатырга теләмичә генә бара?

– Хәзерге вакытта вакцинация һәм ревакцинация – коронавируска каршы көрәшүнең төп юлы. Күп илләр шушы юлдан бара. Кызганыч, бу юлда без арттарак. Үлем-китемнәр саны да моны раслый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Вакцина коронавирусның аерым бер штаммы өчен ясала, ләкин бу штамм үзгәргәч, аның нәтиҗәлелеге тулысынча югала дигән сүз түгел. «Омикрон» моңа мисал булып тора: шушы яңа штамм килеп чыгу белән дөньяда кулланыла торган барлык вакциналарның да нәтиҗәлелеге кимеде, тик бетмәде. Ул әле дә авыруның зәһәр формаларыннан саклый.

Бездә вакцинациягә караш кискен дип әйтергә була, бу бер дә сер түгел. Коронавирус белән генә дә бәйле түгел ул, аңа кадәр чорда да вакциналарга мөнәсәбәт каршылыклы иде. Бу тенденция, COVID-19 барлыкка килүгә көчәеп, инде күзгә күренә башлады, шул гына. Зур һәм комплексլы проблема, минемчә. Аның нигезендә җәмгыятьтә бер-беребезгә ышаныч җитмәү ята.

:: Шул ук вакытта, пандемия чорында вакцина ясатырга ярамый да, диләр бит әле.

– Андый фаразлар вакциналар килеп чыккан вакытта гына бар иде, бу фаразлар расланмады.

:: Беренче вакцинадан соң бар кешенең дә иммунитеты формалашмый, антитәнчекләре барлыкка килми. Мондый очракларда нишләргә соң?

– Әйткәнебезчә, вакцина – тылсым түгел. 100 процент нәтиҗә бирә торган вакциналар булмый! Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы вакцинадан соң антитәнчекләр күләмен күзәтеп торырга кирәк дигән киңәш бирми.

Вакцинациядән соң антитәнчекләр барлыкка килмәү, чынлап та, иммунитетның формалашмавын аңлата. Мондый очракларны табиб белән сөйләшергә кирәк. Шуны да әйтим: бездә кулланыла торган вакциналар төрле. Минемчә, фәнни яктан исбат ителгән, дөрес фәнни тикшерүләр үткәрелгән вакцина бездә бер генә, ул да булса – «Спутник». Шушы вакцинаның халыкара оешмалар тарафыннан танылырга мөмкинлеге дә бар. Калган вакциналарның фәнни нигезе шикле дип аңлыйм.

:: Кайберәүләр икешәр, өчәр кат та авырый. Моны ничек аңлатырга була соң, Илдус Җәүдәтович? Иммунитет шулай тиз бетәмени ул?

– Беренчедән, бу яңа штаммнарга бәйле. Күпләр «омикрон» штаммын йоктыра, вакцинадан яки әле яңа гына авырып алганнан соң хасил булган иммунитет авыруны җиңелрәк үткәрергә булыша гына.

Икенчедән, вирусны йоктыру яки йоктырмау иммунитеттан гына тормый. Мин үзем «дельта» штаммы белән 2021 елның августында авырдым, чир уртача авыр формада үтте, үпкәләрем 25 процентка зарарланган иде. Минем, әлбәттә, вакцинам да ясатылган, иммунитетым да бар иде…

:: Менә! Ә нишләп авырдыгыз икән соң?

– Нишләп авырдыммы? Ул вакытта коронавируслы сырхаулар өчен вакытлыча госпитальдә эшләп, вирус белән бик тыгыз «элемтә»дә булганга күрә. Эш иммунитетта гына түгел. Шуңа күрә дә бит битлек, респиратор кию, социаль ара саклау, кулларны дезинфекцияләп тору кебек кагыйдәләр актуальлеген югалтмый.

:: Телебездән «омикрон» сүзе төшми хәзер. Ул аеруча балалар өчен куркыныч, диләр.

– Янә башланып киткән менә шушы коронавирус дулкыны, чынлап та, яңа штамм – «омикрон» га бәйле. Моңа кадәрге штаммнар балалар өчен бик йогышлы түгел иде, шуңа да әүвәлге дулкыннарда авыручы балаларның саны 5–10 проценттан артмады. Яңа штаммның структурасы үзгәрде, ул балалар өчен дә, зурлар өчен дә бер үк дәрәҗәдә йогышлы дип әйтергә мөмкин.

«Омикрон» таралгач, вазгыять үзгәрде, дисәк тә, бу бары тик вирусның йогышлылыгына гына карый. Ә менә чирнең ничек үтүе, аның клиник картинасы үзгәрмәде дияргә була. Күп кенә балалар авыруны җиңел яки уртача авыр формада үткәрә, чынлап торып каты авыручы балалар саны зур түгел.

Проблема башкада – берьюлы күп баланың авырып китүендә бит. COVID-19 белән элегрәк мондый хәл юк иде. Алдагы штаммнар аз йогышлы булганга, авыручы балалар саны да акрын гына артты. Болай итеп берьюлы күп баланың авырып китүе медицина системасында киеренкелек үсүен барлыкка китерә. Педиатрлар, педиатрия ятаклары, хастаханәләр саны чиксез түгел ич!

Мондый очракларда ата-аналарның роле арта. «Кызыл флаглар» дигән төшенчә бар. Балага әти-әни күзлегеннән карап, дөрес бәя бирү системасы бу.

Күпчелек балага табиб кирәк тә булмаска мөмкин. Коткыга бирелеп, авыру сабыйны тегендә-монда йөрткәнче, аны өйдә гап-гади мәтрүшкә чәе эчереп дәвалау дөресрәк. Ә кайбер балаларга кичекмәстән табибка күренү зарур. «Кызыл флаглар» системасы менә шуны аңларга булыша.

:: Бу «кызыл флаглар»ны санап үтегез әле.

– Һәр ата-ана белеп торырга тиеш аларны. Болар: көзән җыеру (судорога), аң буталу, координация белән проблемалар башлану, баланы елатырлык дәрәҗәдә баш яисә эч авырту; 39,5тән югары, берничек тә төшми торган температура яисә өч тәүлектән артык температураның 38дән югары торуы, температураның икенче дулкын булып күтәрелүе; баланың көннән-көн хәле начараю, хәлсезләге; су эчүдән баш тарту, су җитмәү галәмәтләре (бәдрәфкә сирәк йөрү, бәвел төсе куе сары төстә булу, ислөнү, елаганда күз яше бүленеп чыкмыйча гына елау); тын кысылу, авыр итеп, сызгырып сулау; дәвамлы, туктамыйча косу яисә эч киту; тәнгә җете кызыл тимгелләр чыгу; колак, ашый алмас дәрәҗәдә тамак авырту.

Әңгәмәдәш – Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

11 февральдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә бүлек мөдире **Фәния Әхмәтҗанова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

ЯЛГЫЗ ӘБИНЕ ТӘРБИЯЛӘҮ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Күршебездә ялгыз әби яши. Кызы башка шәһәрдә кияүдә. Еш кайтып йөри алмый. Үзе дә олы яшьтә. Шуңа социаль яклау хезмәте аша әнисен карарга берәр кеше билгеләп булмасмы икән дип кызыга. Ул социаль хезмәткәргә күпме акча түләп торасы була икән?

Фәрзәнә ШӘРИПОВА.
Казан

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте:
– Социаль хезмәткәргә түләү күләме нинди хезмәт төре сайлауга, аның ялгыз әби янына атнага ничә тапкыр килүенә карап билгеләнә. Аның нечкәлекләре бик күп. Шуңа күрә сезгә теркәлү урыны буенча социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Белгечләр социаль хезмәткәргә түләү шартларын тәфсилләп аңлатачак.

МИРАСКА ХОКУКНЫ НИЧЕК ТОРГЫЗЫРГА?

Урын өстендә яткан абыемны тәрбияләп, соңгы юлга озаттым. Мин – аның бердәнбер варисы. Мирасны рәсмиләштерү артыннан йөри башлаган идем. Соңга калгансыз, хәзер моны суд аша гына эшләп була, диләр. Шуның тәртибен аңлата алмассызмы икән?

Суфия ХАРИСОВА.
Балтач

Юрист Регина ШАКИРОВА:
– Күпләр мирасны мәрхүмнең вафатыннан соң алты ай узгач рәсмиләштерергә кирәк дип ялгыша. Чынлыкта исә моны алты ай вакыт узганчы эшләргә кирәк. Аннары үз хокукларыңны, дөрестән дә, суд аша гына даулап булачак. Анда да кешегә бер генә мөмкинлек бирелә. Шушы бер мөрәҗәгать итүдә мирасны вакытында рәсмиләштермәвеңне җитди сәбәпләр белән дәлилли алсаң, отасың. Юк икән – мирастан колак кагасың. Сезгә шушы юнәлештә эшләгән юристка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул судта сезнең мирасны вакытында рәсмиләштермәвегезне «кичектерерлек» сәбәп табып, шуны рәсмиләштерергә ярдәм итәчәк. Кеше якынының вафаты турында соң белүе, җитди авыруы, читтә илдә командировкада булуы аркасында да соңарырга мөмкин. Кайберәүләр кеше вафат булгач, аның мирасы автомат рәвештә вариска күчә дип уйлап та ялгыша. Закон тарафыннан билгеләнгән 6 ай вакыт эчендә ул мәрхүм васыять иткән торакның коммуналь түләүләрен түләп торган, берәр кешегә мәрхүмнең бурычын кайтарган булса, яки аның кулында мәрхүм исеменә ачылган саклык кенәгәсе булса, аның мираска булган хокукларын торгызу кыен түгел. Мирастагы өлешен вакытында рәсмиләштергән башка варислар булса, алар ризалыгы белән сезнең хокукларны да торгызырга мөмкин.

ИСКЕ КИЕМНЕ КАЯ КУЯРГА?

Күптән түгел дингә килдем. Яулык япканчы кигән киемнәрне сатсам ярыймы икән?

«Иске таш» мәчет имамы Рамил хәзрәт ЮНЫСОВ:
– Әгәр дин кабул иткәнче кигән киемнәрегез ислам канунннарына туры килмәсә, аны сатмавыгыз хәерле. Башка кешегә бирергә дә киңәш итмәс идем. Безгә туры килмәгән әйбер башка кешегә дә туры килми.

КАБАТ ИСӘПЛӘНӘЧӘКМЕ?

Мин – пенсионер. Гыйнвар башында эштән киттем. Минем пенсиямне кайчан кабаттан исәпләрләр икән?

Равил ХАМАТДИНОВ.
Чаллы

Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге:
– Рәсми рәвештә эштән киткәч, өч айдан соң пенсия кабаттан исәпләнә. Яңа суммадагы пенсияне сез алдагы өч айга өстәмә түләү белән май аенда алачаксыз.

vk.com

СӨННӘТКӘ КАЙЧАН УТЫРТЫРГА?

Улыбызга өч ай. Баланы сөннәткә утырту буенча уртак фикергә килә алмыйбыз. Ирем хәзер сөннәткә утыртыйк, ярасы тизрәк төзәләчәк, ди. Мин кызганам. Өч яшь тирәсендә башкарсак, дим. Баланы наркоз астында да яткырасы килми. Ни эшләргә икән?

Алсу ЙОСЫПОВА.
Арча

Республика балалар клиник хастаханәсенең балалар хирургы Айдар ЗАКИРОВ:
– Ата-аналар арасында, дөрестән дә, бала кечерәк булган саен, авыртуны азрак тоя дигән ышану бар. Чынлыкта бу күбрәк сабыйның психологик яктан өлгермәгәнлеге белән бәйле. Алар әлегә авыртуга зарлана белми, шуңа бу операцияне дә җиңелрәк уздырган кебек тоела. Зуррак бала исә, яраны үз күзләре белән күреп, аның нәрсә икәнен аңлагач, бу процедураны психологик яктан да кичерә. Шунлыктан олырак бала сөннәткә утыртуны авыррак уздырган кебек тоела. Медицинада сөннәткә ике яшьтән соң, наркоз астында гына утыртырга рөхсәт ителә. Бу очракта операция дә сыйфатлы ясала. Бала да азапланмый. Наркоз бала сәламәтлегенә зыян салыр дип тә куркасы юк. Заманча наркозлар, аеруча балаларныкы, бик сыйфатлы, җиңелчә кичерелә. Җирле наркоз сәламәтлек өчен күпкә куркынычрак. Җенес органындагы ялкынсынудан (баланопостит) тилмергән, авырдан сигән (фимоз) балаларга сөннәткә утырту операциясе ничә яшьтә булуына карамастан ясала. Сөннәткә утырту операциясе балага ике яшь тулганчы ук ясалган очракта да ул ким дигәндә дүрт сәгать дәвамында табиб күзәтүе астында булырга тиеш.

Рәхмәт ишетү рәхәт

Зыялы, дини, дөньяви белемле, югары оешмаларда хезмәт куйган җитәкче, хезмәт ветераны, РСФСР, ТАССРның күп мактауларына ия булган, 3 тапкыр хаҗ кылган игелекле зат Сиринә Исмәгыйль кызы Шаһимәрданова – бик күпләргә игелек өләшкән кеше.
10 елдан артык Коръән уку буенча «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесендә һәр балага бүләкләр бирел сөендерә, кайнар ризыклар белән сыйлый ул. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте яусын сезгә! Улыгыз Айдар Шаһимәрдановка һәр эшендә ярдәм итәсез. Олы шәхесебез Әлмира Әдиятуллина башлаган бәйгене дәвам итәсез. Сезгә нык сәламәтлек, зирәк зиһен, хәерле-бәрәкәтле гомер, иман байлыгы, тынычлык, гаилә бәхете телим.

Сәлимә абыстай ХӨСӘЕНОВА.
Казан

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Уйлы күңел уйлана

Бер җылы сүз җитә...

Шушы көннәрдә юбилеен билгеләп үткән бер танышым: «Укып бетергәннән бирле эшләдем. Теләсә нишләп тә йөрмәдем, озаклап авырып та ятмадым, сәбәпсез эш калдырганым да булмады. Минем белән бергә эшләгән кешеләрне алдынгы итеп бүләкләделәр дә, мактадылар да... Ә мин үз гомеремдә бер грамота да күрмәдем», – дип куйды. Уңайсыз булып китте.

Мин нәрсә әйтергә дә белми аптырап торган арада үзе үк, шаяруга борып: «Әй, болай гына әйттем инде. «Тегендә» барырга мактау кәгазе дә кирәкми, исем-медальләр дә сорамыйлар бит», – диде. Мин дә, әрнегән җанын борчымыйм инде дип, сүзне башкага бордым. Әмма трубканы куйганнан соң, күңелендәгесен әйтте бит бу, дип уйландым.

Болай дип әзгәләнүчеләр, ышанам, бер ул гына түгелдер. Бу очракта үземчә аның хезмәтен күрмәүләренә сәбәпләр эзлим: шәһәрдә, зур коллективта бөтен кешене дә күреп, бәяләп бетерә алмыйлардыр инде, дим. Ә үзем шул ук калада да читтәгеләрне дә чит итмәгән коллективлар барлыгын искә төшереп, бу акланууны кире кагам. Төп сәбәпнең авыл яки шәһәргә генә бәйле түгеллеген дә беләм. Авылларда да күләгәдә калганнар күпме бит. Юкса нәрсә инде ул грамота – мактау таныклыгы, рәхмәт сүзе! Аларны бирер өчен зур ачышлар, уңышлар һәм... күп акча да кирәк түгел ләбаса! Бир инде шуны, сәбәбен тап, җылы сүзеңне кызганма. Бу кадәресенә акыл да, зур оештыру чаралары да кирәкми, күңел бирү дә җитә.

Миңа калса, монда тагын шунысы да бик мөһим: һәрбер кеше куйган хезмәтләренә тиешле бәяне, кадер-хөрмәтне эшләп торган чакта – яшь чакта күрергә тиеш. Тамчы кадерләсенә генә дә сөенерлек чакта. Стимул бирү өчен дә кирәктер бу. Дөрес, хәзер яшьләр, бәлки, безненчә уйламыйдыр да инде, алар өчен бу фикерләр, бу бәяләүләр – искелек калдыгыдыр, социализм чоры идеологиясе дип саналадыр? Алар өчен иң шәп стимул – югары хезмәт хакы кебек. Анысы да кирәк. Һәр заманның – үз бизмәне. Тик, анализлап карасаң, берсе икенчесенә һич тә комачауламый. Әнә яшь җырчылар, сәнгать әһелләре, мактаулы исемнәр алгач, шатлыкларын һич тә яшерми бит. Һөнәри бәйгеләрдә җиңүче башкалар да, беренче тапкыр зур сәхнәгә чыгып, гади генә рамга куеп бирелгән мактау кәгазе алучылар да шатлана, аларны социаль челтәрләргә куя (әле үзләре генә дә түгел, якыннары да бүлешә бу шатлыкны). Гаепләп язуым түгел, мондый стимулларга замана яшьләренең дә битараф булмавын гына әйтергә җыенам. Җылы сүзнең әле беркемгә дә артык булганы юктыр, мөгаен (ихластан һәм тиешенчә булса). Шөкер, моны аңлап эш оештыручылар, «бер кулында – кәнфит, бер кулында – чыбыркы» булган, ягъни эшләтә һәм таләп итә дә, хезмәтләрен вакытында бәяли-күрә белүчеләр дә бар. Шул ук вакытта лаеклы ялга китәр вакыты җитеп тә, бер мактау кәгазе күрмәүчеләр дә...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

7 февраль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Черное озеро». Оренбургские гастролеры 16+
00.25 «Башваткыч» 12+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

04.00 Олимпийские зимние игры 2022 г. в Пекине. Фигурное катание. Командные соревнования. Пары (произвольная программа). Женщины (произвольная программа). Танцы (произвольная программа) (S)
08.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Любовь Аксенова, Ирина Пегова, Виктор Сухоруков. «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ» (S) 16+
23.30 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+
01.00 Дневник Олимпийских зимних игр 2022 г. в Пекине (S) 0+
02.05, 03.05 «Время покажет» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине. Биатлон. Женщины 15 км. Индивидуальная гонка
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «СКЛИФОСОВСКИЙ». Новые серии 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине

МАТЧ ТВ

06.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Горнолыжный спорт. Гигантский слалом. Женщины. 1-я попытка. Прямая трансляция
06.40, 09.25, 13.50, 18.30, 22.50 Новости
06.45, 09.30, 13.55, 18.35, 21.30, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
07.05 XXIV Зимние Олимпийские игры. Хоккей. Женщины. Россия – Канада. Прямая трансляция
10.00, 12.50, 17.45, 22.55, 01.45, 04.00 XXIV Зимние Олимпийские игры 0+
11.25 XXIV Зимние Олимпийские игры. Конькобежный спорт. Женщины. 1500 м. Прямая трансляция
14.30 XXIV Зимние Олимпийские игры. Прямая трансляция.
19.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – УНИКС (Казань). Прямая трансляция
22.20 Тотальный футбол 12+
03.55 Новости 0+
04.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фристайл. Биг-эйр. Женщины. Финал. Прямая трансляция

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.40 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «ТРИ ЗВЕЗДЫ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ОБЪЯТИЯ ЛЖИ» 16+
06.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Лужа» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ВЕРНИСЬ В СОРРЕНТО» 16+
19.00 «ЧУЖИЕ ДЕТИ» 16+
23.35 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР». 31-я и 32-я серии 16+
01.30 «Понять. Простить» 16+
02.30 «Порча» 16+
02.55 «Знахарка» 16+
03.20 «Верну любимого» 16+
03.45 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ» 16+
07.00 «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня. 16+
09.20, 02.20 «ЖЕНИТЬБА БАЛЬЗАМИНОВА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости. 16+
14.05, 03.55 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ». 1-я – 4-я серии 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Карим Хакимов». Док. фильм. «Советский паша» 16+
19.40 «Скрытые угрозы». «Альманах №90». Премьера! 16+
20.25 «Загадки века». Премьера! 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем». Премьера! 12+
23.40 «ЭКИПАЖ МАШИНЫ БОЕВОЙ» 12+
01.05 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
03.45 «Оружие Победы». Док. сериал 12+

8 февраль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Моя жизнь – черновик. Марина Цветаева 12+
00.50 «Черное озеро» 16+
01.15 «Реквизиты былой суеты» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.30, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
13.15 Олимпийские зимние игры 2022 г. Лыжные гонки. Мужчины/Женщины. Индивидуальный спринт (S)
15.45, 02.50, 03.05 «Мужское/Женское» 16+
16.40 «Время покажет» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ» (S) 16+
22.30 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.25 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 Дневник Олимпийских зимних игр 2022 г. в Пекине (S) 0+
01.00 Олимпийские зимние игры 2022 г. в Пекине (S) 0+

РОССИЯ 1

04.15 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине. Фигурное катание. Мужчины. Короткая программа
08.30, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.25 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине. Биатлон. Мужчины 20 км. Индивидуальная гонка
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Детективный телесериал «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. «СКЛИФОСОВСКИЙ». Новые серии 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине

МАТЧ ТВ

06.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фристайл. Биг-эйр. Женщины. Финал. Прямая трансляция
06.10 XXIV Зимние Олимпийские игры. Горнолыжный спорт. Супергигант. Мужчины. Прямая трансляция
07.05 XXIV Зимние Олимпийские игры. Хоккей. Женщины. США – Канада. Прямая трансляция
09.25 XXIV Зимние Олимпийские игры. Сноубординг. Параллельный гигантский слалом. Финал. Прямая трансляция
10.50, 13.20, 18.30, 22.40 Новости
10.55, 18.35, 21.50, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
11.25, 19.25, 22.45, 01.45, 04.00 XXIV Зимние Олимпийские игры 0+
13.25 XXIV Зимние Олимпийские игры. Конькобежный спорт. Мужчины. 1500 м. Прямая трансляция
14.50 XXIV Зимние Олимпийские игры. Санный спорт. Женщины. 3-я попытка. Прямая трансляция
16.05, 17.15 XXIV Зимние Олимпийские игры. Хоккей. Женщины. Россия – Финляндия. Прямая трансляция
16.40 XXIV Зимние Олимпийские игры. Санный спорт. Женщины. 4-я попытка. Прямая трансляция
03.55 Новости 0+
05.10 XXIV Зимние Олимпийские игры. Горнолыжный спорт. Слалом. Женщины. 1-я попытка. Прямая трансляция

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.40 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «ТРИ ЗВЕЗДЫ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Только вдвоем» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «НЕОПАЛИМЫЙ ФЕНИКС» 16+
19.00 «КОМПАНЬОНКА» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР». 33-я и 34-я серии 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
02.00 «Порча» 16+
02.30 «Знахарка» 16+
02.55 «Верну любимого» 16+

ЗВЕЗДА

05.25, 14.05, 03.55 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 02.10 «МАЧЕХА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Карим Хакимов» 16+
19.40 «Легенды армии» 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «МИССИЯ В КАБУЛЕ» 12+
03.40 «Оружие Победы» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 7–13 ФЕВРАЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бер дустыгыз үзегезгә нәрсәнедер әйтеп бетерми кебек тоелыр. Бу исә, ачуыгызны китереп, аның белән араларны өзү турында уйланырга мәҗбүр итәр. Атна ахыры эшегезгә бәйле бик кирәкле яңалыклар алып килер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Уңышны «койрыгы»ннан тотып алуның бер кыенлыгы булмаячак. Эш сөючән, сүзегездә нык торасыз бит сез. Шәхси тормышта берникадәр күңел сүрелү булып алса да, яхшыга гына бу!

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Атна башында көч-куәтегезнең чик-чамасы булмас. Иң мөһим эшләрегезне шул чорга планлаштырырга онытмагыз. Җәмгагата таба акча мәсьәләсе итәктән тарта башламагае. Сәбәбе – кирәкмәгәнгә чыгым тотуга ияләшеп бару бугай…

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Эш урыныңда җитәкчегез хезмәтегезне бик яхшылап күреп, аңлап алыр. Озак көттермичә генә, эш хакыгызны әйбәт кенә күтәреп куяр ул. Шулай итеп, көтмәгәндә акча мәсьәләсе дә хәл ителер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Эштә кайберәүләр астыртын гына сезнең хезмәттән файдаланмакчы була. Шуңа күрә сак булыгыз, артык сүз ычкындырмыйча, тыныч кына үз эшегезне белегез. Атна ахырында якыннарыгызның бик әйбәт бер яңалык белән сөендерүен көтегез.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Зур эшләргә тотынмый, киләчәккә планнар кормый торыгыз: вакыты ул түгел. Артыгын кабаланмыйча, иркен сулап кую һәм ял итә-итә генә эшләү чоры бу. Ял көннәрендә сәерррәк, әмма тормыш итү өчен кирәкле бер мәсьәләдә хыялыгыз тормышка ашар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Кырыкмаса-кырык төрле мәшәкатьләрегез, ниһаять, узганда калыр, мәңге дә очына чыгып булмас кебек тоелган проблемаларыгыз хәл ителеп куяр. Нәтиҗәдә күңелегез күтәрелеп китәр һәм якын киләчәккә әйбәт кенә планнар корылыр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бик катлаулы бер эш куштылармы? Ярдәм сорагыз әле, юкса бик авырга туры килмәгәе. Гаилә торкасы булуны хәләлегезгә тапшырып торыгыз – әлегә шулай кирәк. Атна ахырында хезмәт урыныңда килеп туган бер вакыйга киләчәккә шәп кенә өметләр уятыр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Ашык-пошык кына берништи карарга килмәгез, тирә-гездәгеләргә үзегезгә йогынты ясарга ирек бирмәгез. Бик төпле акыл белән эшләү сорала хәзер. Мондый эшнең нәтиҗәсе бик саллы булачак!

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Матди өлкәдә берништи кыенлык булмаячак: акча чын мәгънәсендә ишелеп керәчәк. Әлбәттә инде, күктән яумый ул: тырыш хезмәтегез нәтиҗәсе шулай бик юмарт бәяләнәчәк.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Катлаулырак чор. Аның каравы әҗерле булачак ул. Белеп торыгыз: дусларга түгел, ә гаиләгә таяну чоры. Кайбер планнарыгыз барып чыкмаячак. Әмма тиздән моның файдага гына булуын аңларсыз.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
«Һәр ялтыраган алтын түгел». Бу атнада шушы гыйбарәне истә тотыгыз. Яңа танышларыгызга ышанмагыз. Атна уртасында гаилә муллыгын арттыруга бәйле әйбәт хәбәрләр ишетерсез.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

Ярдәм кирәк кешегә сиделка хезмәте күрсәтәбез. «Помощник» социаль хезмәте
БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН:
8 (929) 962-76-44

ХАТЫН-КЫЗНЫҢ – ҮЗ КӨЗЕ

Хатын-кызның язы гына түгел, көзе дә була. Соңгысы барыбызга да таныш – климакс чоры. Берәүләр аны тормышның икенче бер кадерле өлешенә аяк басу дип саныса, кайбер гүзәл затлар организмның картаюын бик авыр кабул итә. Соңгы елларда климаксның яшәрә баруы да күпләрне хафага сала. Әлеге чорга алдан әзерләнергә кирәкме? Аны җиңелрәк уздыру өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-гинеколог Диләрә МӨХӘММӘТОВА белән әлеге сорауларга җавап эзләдек.

pixabay.com

• **НИДӘН ГЫЙБАРӘТ?** Хатын-кыз тормышындагы менопауза, икенче төрле итеп әйткәндә, климакс чоры күрем килү чорының тәмамлануыннан гыйбарәт. Бу чорда күкәйлекләр дә табигый эшчәнлегеннән туктый. Россиядә яшәүче гүзәл затларның климакс чоры уртача 49–51 яшьләргә туры килә. Ул 40 яшькә кадәр үк башланса, иртә климакс санала. Операция аркасында күкәйлекләрен алдырырга мәҗбүр булган хатын-кызлар да еш кына менопауза чорына иртәрәк аяк атлый.

• **НИ СӘБӘПЛЕ ЯШӘРӘ?** Бу, иң беренче чиратта, хатын-кыз организмының үзенчәлекләренә бәйле. Фәндә «күкәйлекләрнең вакытыннан алда сафтан чыгуы» дигән төшенчә бар. Андый чакта хатын-кызда климаксның беренче билгеләре 40 яшькә кадәр үк күренә башлый. Бу организмдагы генетик үзгәрешләргә бәйле булырга мөмкин. Калкансыман биз, бөер өсте бизләре дөрес эшләмәү аркасында да климакс иртә башлана. Моннан тыш хатын-кызның даими рәвештә стресс кичереп яшәве, дөрес тукланмавы да менопаузаның иртә башлануына китерә ала.

• **НИЧЕК ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ?** Хатын-кыз үз сәламәтлеген климакс алдыннан гына түгел, гомер буе кайгыртырга тиеш. Сәламәт яшәү рәвеше алып барган, һәрчак хәрәкәттә булган, дөрес тукланган, гәүдә авырлыгын контрольдә тоткан хатын-кыз климакс чорын җиңелрәк кичерә. Бу чорга физик яктан гына түгел, рухи яктан да әзер булырга кирәк. Юкса күп кенә хатын-кызлар климакс чорында организмының ни рәвешле үзгәреш кичерәчәген күз алдына да китерә алмый. Климакс вакытында гүзәл затны кинәт кенә тәнгә кайнар су койгандай өянәкләр борчый башлый. Хатын-кызның кәефе еш үзгәрүчәнгә әйләнә, йокысы бозыла, аналык җиңсәсендә корылык сизелә. Бу билгеләрнең берсе генә күзәтелсә дә, табибка күренүең хәерле.

• **НИЧЕК ДӘВАЛАНЫРГА?** Климаксны дәваларга кирәкми, үзе үтә ул дигән сүзне еш ишетергә туры килә. Бу – ялгыш фикер. Климаксны дәваларга кирәк. Шушы чорга аяк баскан хатын-кыз даими рәвештә табибка күренеп торырга тиеш. Климакс чорында ничек дәваланырга кирәклеген дә бары тик табиб кына билгели ала.

• **НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?** Климакс чорында нәрсә белән туклануыбыз да зур әһәмияткә ия. Кайбер төр продуктлар шушы чордагы өянәкләрне, үзгәрешләрне җиңелрәк уздырырга ярдәм итә. Климакс башланган гүзәл затларга кузаклыларга, бодай, дөге, ясмык, җитен ярмаларына, көнбагыш, кукуруз, имбиргә өстенлек бирергә киңәш итәр идем. Финик, гранат, кызыл виноград, алмада да организмдагы шушы үзгәрешләрне җиңелрәк уздырырга ярдәм итүче матдәләр бар.

• **НӘСЕЛДӘН КҮЧӘМЕ?** Климаксны кызы да әнисе кебек уздыра, дигән сүз дөрес түгел. Һәр хатын-кыз бу чорны индивидуаль рәвештә уздыра. Ул нәселдәнлеккә берничек тә бәйле түгел.

Үзем сынадым

ШАЛФЕЙ БУЛЫША

Ике ел элек климакс башланды. Тәнгә эссе бәргән чакларда үлеп бетәм. Соңгы арада шул вакытта бер төнәтмә эчеп куя башладым. Булыша. Җайлы ясала да. 2 чәй кашыгы вакланган шалфей яфрагы белән 1 чәй кашыгы наратбаш үләнен ваклап болгатасың да, өстенә 2 стакан кайнар су салып, 1 сәгать төнәтәсең. Шуны тәнгә эссе бәргән чакта эчеп куясың. Шуны эчкәч, хәлем күзгә күренеп яхшыра.

Әлмәттән Фирая Г.

Белеп тор!

Сагыз турында 3 уйдырма

1 «Сагыз чәйнәү ашыйсы килүне баса». Сагыз аппетитны киметми. Авызга сагыз килеп керүгә, селәгәй бүленеп чыга. Ашказаны ризык эшкәртергә әзерләнә башлый. Организмга ризык кермәгәч, ашказаны бушка эшләп утыра булып чыга. Бу исә аның лайлалы тышчасына зыян салырга мөмкин. Гастрит, панкреатит, ашказаны җәрәхәте кебек хроник ашказаны-эчәк авырулары баш калкыткан чорда сагызны бөтенләй чәйнәргә ярамый.

2 «Сагыз тешләрне чистарта». Күпләр сагызны ашаганнан соң теш чистарту, авызга хуш ис кертү максатында куллана. Әмма ул теш щеткасы белән пастасын һич кенә дә алмаштыра алмый.

3 «Шикәрсез сагыз файдалырак». Мондый сагызларның составында, гадәттә, сорбит, ксилит, мальтит, аспартам кебек шикәр алыштыргыч матдәләр була. Сорбит белән ксилит – табигый балландыргычлар. Сорбит виноград, алма һәм миләштән табыла. Ксилит исә кукуруз чәкәне тышчасында, бөртекләләр кабыгында бар. Ясалма баллындыргычлар рәтенә кергән аспартам исә нерв системасын зарарларга мөмкин, дип кисәтә белгечләр. Сүз уңаеннан, ксилит белән сорбит калория ягыннан гадәти шикәр белән бертигез. Шуңа күрә «шикәрсез» сагыз чәйнәү кешенең тән авырлыгына да, кандагы шикәр күләменә дә гадәти шикәр кебек тәэсир итәчәк.

Киңәш-табыш

Укроп ютәлне баса

1 аш кашыгы укроп орлыгын 1 стакан кайнар суга салып, кайнап торган сулы икенче савытта 15 минут җылытырга кирәк. Шуны 45 минут төнәткәч, сөзеп, көненә 4–5 тапкыр 1–2шәр аш кашыгы эчәсе.

ДЕПРЕССИЯДӘН КОТКАРА

Депрессиядән коткаручы төнәтмә өчен 500 грамм сельдерей тамыры, 50 грамм керән тамыры, 1 лимон, 50 грамм сарымсак белән 50 грамм бал кирәк булачак. Сельдерей, керән, сарымсак һәм лимонны иттарткыч аша чыгарып, шушы катнашмага бал өстәгез. Алга таба аны банкаларга тутырып, бер атна төнәтегез. Аны көнгә бер чәй кашыгы күләмендә ач карынга эчәргә кирәк. Төнәтмәне суыткычта саклыйсы. Күңел төшенкелеге белән йокысызлыктан интегүчеләргә түбәндәге ысулның да ярдәме тими калмас. Бер стакан кайнап торган суга 1 аш кашыгы вакланган бөтнек яфрагы салып, ун минут кайнатырга кирәк. Аны көн саен иртә-кич ярты стакан күләмендә эчсәгез, хәлегезнең яхшыруын сизәрсез.

Исеңдә тот!

ПЕСТӘ ЧИКЛӘВЕГЕ ЙОКЛАТА

Йоклый алмыйча ятсагыз, пестә чикләвеге (фисташка) ашагыз! Аның составында йокыга талырга ярдәм итә торган магний, аксым, B_6 витамины бар. Даими рәвештә пестә ашаган кеше тынычлана, арыганлыктан котыла, стресслрга бирешми. Фисташка яшелрәк булган саен сыйфатлырак санала. Ул А, B_1, Е витаминнарына, тимергә дә бай. Алар хисабына ул организмны ныгыта, йөрәк тибешен җайга сала, баш мие, бавыр эшчәнлегенә уңай тәэсир итә, канны чистарта, ир-атның җенси куәтен арттыра.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ОРЛЫКНЫ НИЧЕК САЙЛАРГА?

Табигатьтә әле кыш хакимлек итсә дә, орлык сатыла торган кибетләргә җан керде. Кыштырдап торган матур рәсемле каплардагы орлыкларны сурәтендәгечә үстерәсе килә дә бит! Ләкин кайчак бөтенләй тишелми яисә рәсемендәгечә булмыйча, кәефне төшерә. Ә шулай да әйбәт орлыкны ничек сайларга соң? Әлеге сорауга ачыклык кертү өчен, бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВАга мөрәҗәгать иттек.

Ничек эшкәртелгән?

Иң элек орлыкларны эшкәртү ысулларын белеп тору зыян итмәс.

• **Лазер белән эшкәртелгән.** «Уңыш бирүчәнлеген арттыру өчен, орлыкларны эшкәртүнең әйбәт ысулы бу, әлбәттә, – ди Эльмира ханым. – Тик 10 көн узганнан соң ук, аның файдасы юкка чыга». Шулай итеп, әлеге ысул башлыча маркетинг хәйләсенә генә кайтып кала. Мондый орлыкны алудан мәгънә юк.

• **Плазма белән эшкәртелгән.** Яраклылык вакытын озайту өчен, шундый юл белән эшкәртәләр. Бу очракта аның яраклылык срогы 2–3 елга озая.

• **Тышчалы.** Гадәттә кишер, петрушка, сельдерей ише вак орлыкларны файдалы микроэлементлардан торган тышча белән берничә кат каплыйлар. Мондый орлык тишелсен өчен, туфракның бик дымлы булуы кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кайдан сатып алырга?

Иң яхшысы – орлыкны төрле күргәзмәләрдән алу. Орлыклар бирегә, арадашчыларны читләтеп, турыдан-туры җитештерүчеләрдән килеп керә. Алар сыйфатлы булулары өстенә, арзанрак та тора. Күргәзмәдә белгечләрдән киңәшләр дә алырга мөмкин. Шулай ук бакча үзәкләрендә дә әйбәт шартларда саклаган сыйфатлы орлыклар сатыла. Ассортименты зур булганлыктан, җаның ниндиен тели, шундыен сайлап алырга мөмкин. Интернет-кибет аша алынган орлыклар да начар түгел. Җитештерүчеләр үзләренең абруен төшерергә теләми, шуңа күрә сыйфатын, аны саклау һәм китерү шартларын бик төгәл үтәргә тырыша. Ә менә ачык базарлардан, азык-төлек кибетләреннән сатып алу киңәш ителми. Ник дигәндә, аларда орлыкларны саклау шартлары тудырылмый. Әйтик, базарда бер суык, бер җылы һавага эләгеп, орлык сыйфатын югалта. Гадәти кибетләрдә тәрәзәләрдән яктылык төшү дә зыян сала.

Гибридмы әллә сортлымы?

Гибрид һәм сортлы орлыклар була. Гибрид орлык тиз тишелә, үсемлекнең иммунитеты нык була, уңышны мул бирә. Мондый орлык капларына «F1» дип языла. «Filgi» дигән сүзнең беренче хәрефе бу. Итальянчадан «сортлы ата-ана баласы» дигәнне аңлата. Ә 1 саны – «беренче буын» дигән сүз. Гибрид орлыктан үскән үсентенең бердәнбер кимчелеге шул: орлыкларын алып калудан мәгънә юк, ул уңыш бирмәячәк. Сортлы орлык исә экономияле кешеләр өчен әйбәт. Уңышны гибрид кебек үк мулдан бирмәсә дә, орлыгын алып, киләсе елда чәчәргә мөмкин.

Нинди каптагысы яхшырак?

Орлык каплары төрле материалдан ясала. Кәгазьдән генә түгел, металл катыштырылган, пластик, полиэтиленнан эшләнгәннәре була. Иң яхшысы – фольга һәм полиэтилен пленка катламнарыннан яки ике катлы фольгадан торган кап. Мондый капларда теләсә кайсы орлык ике ел дәвамында сыйфатын җуймыйча саклана. Ә кәгазь каплардагы орлыкларны, саклау вакыты озаграк күрсәтелсә дә, бер ел гына сакларга мөмкин.

Эльмира Исхакова киңәшләре

✓ Орлыкны җитәрлек итеп кенә түгел, артыгы белән, шул ук вакытта төрле җитештерүчеләрнекен һәм төрле сортларын алырга тырышыгыз.

✓ Орлыкны алганда, кап тышына язылган куллану вакытын игътибарсыз калдырмагыз. Кыяр орлыгы – тишелеп чыгу үзенчәлеген 3–4 ел, помидор – 2–3 ел, кәбестә – 5 ел, ә кишер орлыгы 4 ел югалтмаска мөмкин.

✓ Читтән кайткан орлыкларга кызыкмагыз. Затлы каплы, кыйммәтле орлык әйбәт дигән сүз түгел. Шул ук вакытта рәсемсез генә, гади капларга тутырылган орлыкларны алудан курыкмагыз. Беренче елда алар әйбәт кенә уңыш бирәчәк.

✓ Орлыкны куллану вакыты капка штамп белән куелырга тиеш. Типография шрифты белән язылган икән, димәк, кап алдан ук әзерләнеп куелган. Ягъни чынлыкта анда кайчан һәм нинди орлык салынганлыгы билгесез.

Бакчачыга

Ай календаре

Ай фазаларының үсемлекләр үсешенә йогынты ясавы фәнни расланган. Тәҗрибәле бакчачылар моны бик яхшы белә. Шуңа күрә алар орлыкларны чәчү, үсентеләрне утырту өчен Ай календарен кулланырга тырыша.

ОРЛЫК	ФЕВРАЛЬ	МАРТ	АПРЕЛЬ	МАЙ
Помидор	12-15, 21-25	3-8, 11-17, 20-25	3-5, 7-12, 21, 22	2, 5-12, 14, 15, 17-29
Кыяр, шулай ук карбыз, кавын	12-14, 21-23, 25-27	3, 6-8, 11-13	3-5, 7-10, 25-27	2, 5-7, 14, 15, 18-24, 27-29
Кәбестә	12-14, 21-23, 25-27	3-17, 20-31	3-10, 21, 22, 25-30	2-7, 14, 15, 17-27
Фасоль, борчак, кукуруз	–	11-13	7-10, 14, 15, 17, 21, 22	1, 2, 7-10, 12-20, 24-25
Яшел тәмләткечләр (яфраклы петрушка, укроп, сарымсак, яфраклы салат, кинза, керән)	12-14, 21-23, 25-27	3-17, 20-31	3-10, 21, 22, 25-30	2-7, 14, 15, 17-27
Кабак, ташкабак, патиссон	–	3, 6-8, 11-13	3-5, 7-10, 25-27	2, 5-7, 14, 15, 18-24, 27-29
Кишер, редис, чөгендер, тамырлы петрушка	–	6-8, 11-13, 20-31	3-5, 7-10, 17-22, 25-30	2, 5-7, 10-12, 17-25, 27-29
Татлы борыч, баклажан	12-15, 21-27	3, 6-8, 11-13, 20-31	3-5, 7-10, 21, 22	2, 5-12, 17-24, 27-29
Бакча җиләге	–	–	7-10, 15-17, 22-26, 28-30	1, 2, 5-10, 12-15
Суган	–	–	19-24	18-21
Бер еллык чәчәкләр (петуния, сальвия һ.б.)	17-23	3-16, 20-21	3-7, 12-15, 21, 22	2-5, 12-14, 18-25
Бәрәңге	–	–	17-24, 28-30	1, 2, 5-10

Аш-су

ЛӘВӘШТӘН ПИЦЦА

Лилия Миңнегалиева рецепты

Кирәк булачак: *1 әрмән ләвәше, 1 стакан сөт, 3 йомырка, 2 тырнак сарымсак, тәмнә карап тоз, борыч, ысланган паприка (булмаса да ярый).*

Эчлеге өчен: *пешкән тавык ите (сосиска, колбаса, гөмбә), 1 помидор, 1 татлы борыч, бераз сыр. Пицца өчен иң яхшысы – пешкәч, бик әйбәт сузылучан моцарелла сыры.*

Ләвәшне рулет кебек төреп, ваклап турыйбыз һәм төбе майланган табага бушатабыз. Тирән эчле савытка сөт салып, шуңа 3 йомырка сытабыз, тәмләткечләр, изелгән сарымсак өстибез. Барысын бергә болгатып, вакланган ләвәшкә салабыз. Өстенә, пиццаны нәрсә белән пешерергә яратабыз, шуны – әйтик, пешкән тавык итен, помидор, татлы борыч турап салабыз. Өстенә сыр уабыз. Табаны капкач белән каплап, газ өстенә салмак кына утка куябыз. Кырыйлары алсу төскә кергәнче, 20 минут чамасы пешерәбез.

Валентина СЕМЁНОВА әзерләде

БАЙЛЫККА КЫЗЫККАН КЕШЕ ФӘКЫЙРЬЛЕК ИШЕГЕН АЧАР

Адәм баласының бай яшисе, мөлкәтле буласы килә, бу – аңа хас табигый ихтыяҗ. Әмма акчаны барысыннан да өстен күреп, аңа табынып яшәү дә хәерле түгел. Акча, байлык, мал-мөлкәт – сынаумы? Динебез күп итеп акча эшләүне хуплыймы? Булган байлыкны кайда сакларга һәм бәрәкәтен ничек арттырырга?

Әлеге сораулар белән «Мәрҗани» мәчетенең икенче имамы Айморат хәзрәт ХАҖИЕВка мөрәҗәгать иттек.

:: Хәзрәт, акча яратмаган кеше юктыр ул. Шулай да туймас җаннар да очрый. Акчага табыну турында диндә ни диелә?

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү. Аллаһы Тәгалә безне үзенә буйсыну, ул кушканнарны үтәү һәм тыйганнарыннан тыелу өчен яратты. Шул ук вакытта Аллаһы Тәгалә: «Кешене шулай яратырмын: ул гел нәрсәгә дә булса мохтаҗ булыр», – дип тә әйтә. Аллаһы Тәгаләгә ышанмаган кешене бу дөньяның байлыгына, зиннәтенә мохтаҗлык кичерерлек итеп яраткан. Димәк, дөрестән дә, акчага туймас җаннар бар. Һәр адәм баласының бай буласы килә. Аллаһы Тәгалә безне андый көннәргә калдырмасын иде. Әгәр дә адәм баласы бу дөньяның матди ягын сайласа, аңа фәкыйрьлек ишеге ачылыр, диелә.

:: Коръәндә «Сезне сынармын» дигән сүзләр бар. Акчасызлык һәм, киресенчә, зур байлык – сынаудыр инде ул?

– Әлбәттә. Аллаһы Тәгалә, адәм баласы бу дөньяга килгәч тә, һәрвакыт сыналып торыр, ди. Байлык белән дә, фәкыйрьлек белән дә сынармын, дигән. Әмма алар гел бер үк вакытта, бер үк кешедә генә булмас. Инсаннарга сабырлык кылырга гына кала. «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сабыр итүчеләр белән», – диелә. Акчасызлык дигәндә, кешенең теге яисә бу нәрсәгә мохтаҗлыгын күздә тотабыз. Аллаһы Тәгалә сынаса да, кеше үзен хайваннарча тотарга тиеш түгел. Әйтик, ачлык килсә, кеше, акча дип, әллә нинди адымга барырга – туганын сатарга, фәхешлек кылырга, явызлык юлына басарга мөмкин. Ә бу – шул дәрәҗәгә төшмәс өчен сынау бит. Бай булганда, Аллаһы Тәгалә фарыз кылган зәкят күләме турында онытмаска кирәк. Байлык-мөлкәтеңнән өлеш чыгару – синең бурычың. Пәйгамбәребез: «Әгәр дә син кич белән йокларга ятканда, синең күршеләрең ач икән, син минем өммәтемнән түгел», – ди. Ягъни син бай булып, күршеләрең мохтаҗлыкта яши икән, синең иманың камил түгел.

:: Диндә күп итеп акча эшләргә теләү хупланамы?

– Дин юлында булу дигәч тә, бу бит әле фәкыйрь булырга кирәк дигән сүз түгел. Андый тыю юк. Иң мөһиме, әгәр дә баерга, күп итеп акча эшләргә ниятең бар икән, бу хәләл юл белән башкарылырга тиеш. Хәрам юл белән килгән байлыкның хәере дә юк, ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан кабул да ителмәс. Аның зыяны гына булыр. Син баесаң, мохтаҗларга, фәкыйрьләргә ярдәм итәргә мөмкинлегең артачак. Бу – әлбәттә, файдалы, яхшы гамәлдер. Хәрам малдан Аллаһы Тәгалә саклаcын. Акчаң, байлыгың булган саен, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен өлеш чыгару фарыз.

:: Ришвәт алу, бирү турында ни диелә?

– Ришвәт алырга да, бирергә дә ярамый. Пәйгамбәребез: «Ришвәт алганны да, биргәнне дә Аллаһы Тәгалә ләгънәт кылды», – ди. Бу – тыелган гамәл.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ФӘКЫЙРЬЛЕКТӘН КОТЫЛУ ДОГАСЫ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

«Бисмилләәһи галәә нәфсии вә мәәлии вә диинии. Әллааһүммә раддыйнии бикадааикә вә бәәрик лии фиимәә куддира лии хәттәә ләә үхиббә тәгъҗиилә мәә әххартә вә ләә тәәхира мәә гаҗҗәлтә».

Мәгънәсе: «Үзем, малым һәм динем турында Аллаһының исеме белән сөйләрмен. Аллаһым! Тәкъдир һәм хөкемеңә мине риза кыл, миңа тәкъдир ителгән нәрсәләрне бәрәкәтләндер. Шулай ки, соңга калдырганыңны хәзер бир, хәзер бирәчәгеңне соңга калдырма».

:: Акчаны банкта саклау дөресме?

– Ислам дине хокукы юнәлешендә бу мәсьәлә өйрәнелә. Булган акчаны өйдә, мендәр астында саклап булмый бит инде. Бу куркыныч та. Банкта сакларга мөмкин, куркынычсызрак та.

:: Инвестицияләр турында күп сөйлиләр хәзер. Болар диндә тыелмыймы?

– Юк, тыелмый. Бу хуплана. Әлбәттә, ул җәмәгать өчен файдалы инвестиция булса, хәрам булмаса гына! Инвестиция – үзенә күрә ярдәм итү чарасы да. Пәйгамбәребез чоры мисалында карыйк. Ул берәр эшкә тотынганда, сәхабәләргә мөрәҗәгать иткән, «Бу эштә кем ярдәм итә ала?» – дип сораган. Ярдәм итә алган кешеләр хәзерге инвесторлар кебек бит.

Хәзерге вакытта биткоин турында күп сөйлиләр. Аны, хәрам, диләр. Ул акча саналмый. Диндә дә син күргән, син тотып карый, кулга алырга мөмкин булган нәрсәләргә игътибар бирелә.

Белеп тор!

ӘЗЕРЛЕК БҮГЕННӘН БАШЛАНА

Рәҗәб аена аяк бастык. Рамазан аена 2 ай вакыт калып бара. Әзерлекне бүгеннән башлау зарур, димәк.

Рәҗәб сүзе «тәрҗиб» сүзеннән алынган. Тәрҗемәсе «хөрмәтләү», «табыну» дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә бу айны хөрмәтләп ураза тотучының һәм үзенә дога кылучының гөнаһларын кичерә, аны югары дәрәҗәләргә ирештерә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдистә: «Рәҗәб – Аллаһның ае, Шәгъбән – минем аем, ә Рамазан – өммәтемнең ае», – дип әйткән.

Рамазан алдыннан килгән Шәгъбән һәм Рәҗәб айлары – үз-үзеңне рухи, физик яктан чыныгуга, әзерләүгә, үзгәрүгә этәргән айлардандыр. Рәҗәб аенда кылган изге гамәл-гыйбадәтләр өчен Аллаһы Тәгалә савапларны да арттырып бирә, шул сәбәпле аларны күбрәк кылу бик тә әһәмиятле.

Рәҗәб аен мөселманнарга ничек үткәру тиешле соң? Бу айда кылына торган күркәм гамәлләр:



pixabay.com

- ✓ сәдакалар бирү;
- ✓ фәкыйрьләрне, мескеннәрне шатландыру;
- ✓ вакытында укылмаган намазларны каза кылу;
- ✓ «Ихлас» сүрәсен еш укү;
- ✓ нәфел уразалары (Рамазаннан тыш тотыла торган ураза) тоту.

Сорау – җавап

Коръән турында ни беләбез?

▶ **Коръәндә иң озын сүрә кайсы?**
«Әл-Бәкара» сүрәсе.

▶ **Ә иң кыска сүрә?**
«Әл-Кәүсәр» сүрәсе.

▶ **Коръәнне башкача тагын ничек атыйлар?**
«Әл-Китаб», «Әл-Кәрим», «Әл-Кәләм», «Әл-Фуркан» һ.б.

▶ **Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) Коръән бер үк вакытта һәм тулы күләмдә иңгәнме?**
Юк, аять-аять, сүрә-сүрә индерелгән.

Өч хәдис

- «Иман китермичә җәннәткә кермәссез, бер-берегезне яратмыйча иман китермәссез».
- «Минем өчен яратышканнарны, Минем өчен очрашучыларны, Минем өчен бер-берсенең хәлләрен белүчеләрне, Минем өчен бернәрсәләрен дә кызганмаучыларны Мин дә яратачакмын».
- «Дөреслектә, эшләр ният белән генә бәяләнәләр. Һәр кешегә үзе ирешергә ниятләгән нәрсә генә булачак».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

АЗАТ ФАЗЛЫЕВ:

«АВЫРЛЫКЛАР МИНЕ КӨЧЛЕ ИТӘ»

Татар эстрадасының танылган җырчысы, җор телле Азат Фазлыевны кемнәр генә белми инде? Бүген ул – «Ни хәл?» сәхифәсе кунагы.

:: Азат, нихәл?
– Аллага шөкер! Кремльдән чыгып киләбез. Алсуым белән кызым Зифаны тарихи фильмда төшерергә чакырдылар – менә бергәләп машинага атлыйбыз.

:: Тормышыңның көне-сәгате планлаштырылган. Уф, арыдым, туйдым, дигән чакларың буламы?
– Арыдым, дигән сүздән куркам. Ир-ат ничек арысын ди?! Ул сүзне әйтми генә ял итеп алырга, ял оештырырга тырышам. Әмма мин озаклап ял итә торган кеше түгел – эшсезлек, хәрәкәт булмаудан да куңелсез нәрсә юк.

:: Ә менә Алсу белән гаиләдә дә, иҗатта да, бизнесыгызда да гел янәшә булу арытмыймы? Арадагы тансыклык, сагыну кебек хисләрне кысрыклап чыгармыймы ул?
– Без бер-беребезгә ир белән хатын гына түгел бит, без – дуслар да, хезмәттәшләр дә, киңәшчеләр дә. Иң якын, иң ышанган кешем – Алсу. Ул – гомумән, глобаль масштабтагы кеше: кайнап яши торган, батырып эшли белүче, кирәктә канатландырып җибәрүче. Мин аңа ышанган кадәр беркемгә дә ышанмыйм.

:: Бер сүзеңә бәйләнәм инде менә хәзер. Ир белән хатын-кыз арасында дуслык була аламыни ул?
– Ничек инде гаилә булып яшәгәндә ир белән хатын-кыз арасында дуслык булмасын! Бу сүз белән килешмим. Бер-береңә тартылуны, химияне бетермәс өчен дә тырышырга кирәк – алайса, көндәлек мәшәкатьләр баштанаяк күмеп китәргә күп сорамый.

:: «Ир кешенең бәхете – хатыннан» дигән сүз белән килешми булдыра алмыйсың инде...
– Килешәм. Хатын-кыздан күп әйбер тора. Нәфис кенә булсагыз да, җилкәгезгә күп йөк өелә инде – өйне дә, ирне дә, балаларны да гөл итеп тотарга, ресурста булырга, үз-үзеңне карарга... Шул арада ял итәргә дә өлгерергә кирәк, туганнарны да җыеп торасы. Әнием исән чакта киленнәрен мактап туймый иде, Алсуны да бик үз итте. Хәзер дә Алсу, минем әти булсынмы ул, үзенең әнисеме, абыем Маратлар гаиләсе килеп керәме, апам Розаларны – шат елмаеп, мул өстәл белән каршы ала. Ничек менә шул хатынны мактамыйча була ди?!

:: Карантин күп җырчыларның көймәсен комга терәгәндә, сез челтәрле бизнес белән калкып чыктыгыз.
– Челтәрле бизнес ул – безнең тормыштагы яңа һөнәр. Тотынмас борын, мин моны белмим, миннән булмый, диючеләр бар. Аны кем белеп туган инде? Әллә мин һөнәрем буенча сатучымы? Челтәрле бизнеска да өйрәнергә була – теләк кенә булсын. Без әлеге бизнеска карантинга кадәр үк килгән идек, бүген заказ бар, иртәгә юк булган эстрадага гына ышанып ятып булмый бит.

Блиц-сораштыру

– Светофорның кызыл утына узып киткәнең бармы?
– Күрмәдем *(елмая)*.
– Ресторанда официант өстеңә кайнар аш түкте ди. Беренче реакциян?
– Ачуланмыйм, кем белән ни булмас. Минем машинада запас кием һәрвакыт бар.
– Елаганың бармы?
– Әйтмим...
– Йокыдан торышка Азат Фазлыев иң беренче эш итеп...
– Гаиләмне кочаклыйм.

:: Кара пиар, хайп дигән нәрсәләрне кашыклап түгел, чүмечләп өстәп торалар – сындырмыймы? Тез астына китерел сукканда, тормышка җавабың нинди?
– Кара пиар ул – безнең үсешнең бер баскычы гына: мин аларны түгел, алар бит мине сөйли. Ә минем беркемне каралтканым юк – бизнесыбыз хәләл, беркемне алдаганыбыз, хәрам акчага омтылганыбыз юк. Сәхнәдә чыгыш ясый гына башлаган елларда бер легендар артистыбыз миңа кыска гына итеп: «Энем, сәхнәдә җырлыйсың килә икән, агына да, карасына да әзер бул – шул синең үсешең турында сөйләр. Тик торган атны камчыламыйлар, эшләгән атны гына», – дигән иде. Кайбер кешеләр үзләре дә эшләми, уңышка ирешкәнне дә күрергә теләми. Ә мин аларга ихластан бәхет телим!

:: Азат Фазлыевның күпбалалы әти икәнен беләбез. Усал әтиме икән ул? Балаларына игътибары җитә дип уйлыйсыңмы?
– Искитмәле әти ул *(көлә)*! Алсу әйтүе буенча да, мин – яхшы әти, балалар да аңа кушыла... Зифа тугач, мин бөтенләй үзгәрдем инде. Эреп беттем дисәм дә була. «Җитте күлмәк алып кайтырга!» – дип шелтәләп тә алды әле Алсу. Миңа шуңа кызлар киеме сатыла торган кибеткә керергә ярамый. Егетләр белән кайвакыт усал да булгалыйм, анысы да – тәрбия өчен кирәкле нәрсә.

:: Планнар белән яши торган кешеме син?
– Мин хыял белән яшимендер. Хыял планга әверелә. Планнар уңышларга илтә. Шуның өчен үз-үзеңне җәлләмичә тырышып эшләргә кирәк.

:: Иҗатың икенче планга күчмәгәндер бит? Син аңа үзең нинди бәя бирер идең – тулы канлымы ул яисә нәрсәгә дә булса кытлык кичерәме?
– Безнең үзебезнең тамашачы бар. Иҗат итәбез, туктаган юк – яңа җырлар туып тора. Аны тамашачыга илтеп җиткерү өчен шактый матди әзерлек кирәк булган юлны үтәргә кирәк. Иҗатка бервакытта та көчне дә, егәрне дә җәлләгән юк. Ә бәяне тамашачы бирсен.

:: Күзне йомып, хыялларга чумганда, киләчәгеңне – ак сакаллы карт булган Азатны – ничек итеп күрәсең?
– Йортыбызны матур итеп эшләп бетерер, мунчалар, террасаларны җиткезеп, шимбә-якшәмбегә мунчабәлешкә балаларыбыз-оныкларыбызны көтеп алган нигез хуҗасы итеп күз алдыма китерәм. Янәшәдә – Алсуым. Артыгы кирәкми дә. Ә матди якны башы эшләгән, тырышлыгы булган һәркем кайгыртып яши ала ул...

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Фәнүзә Сәрдекбашта бер ай элек кунак булып киткән. «28 декабрьдә кайтты, 4есе озаттык. Аннары җәй көне Сабантуй җиткәнне көтәбез инде», – ди әтисе. Билгеле булганча, Кадыйровларның уллары Булат та хоккей уйный. Инде менә кече кызлары Айзилә дә шул юлдан киткән. 17 яшьлек туташ Түбән Новгородтагы СКИФ клубының яшьләр командасында чыгыш ясый. Башта Кукмарада фигуралы шуу белән шөгыльләнгән. Ләкин кәшәкәгә тартылу үзенекен иткән. Ике мәртәбә Универсиада чемпионы булып танылган тәҗрибәле апасының киңәше белән Айзилә дә хоккейга күчкән. «Ягуар» командасында уйный башлаган. «Ике ел рәттән Сочи, Пермьгә барып йөрдек. Малайлар арасында булса да, яхшы уенчы саналды. Аннары Түбән Новгородка озатып җибәрдек», – ди Фәһим Кадыйров.

Фәнүзә КАДЫЙРОВА,
ике мәртәбә Универсиада чемпионы:

> Минем хакта «итәкле Овечкин» дип әйтүләре күңелле, әлбәттә. Әмма журналистлар бик нык арттыра. Беркайчан да андый спортчылар дәрәҗәсенә күтәрелә алмаячакмын. Алар белән чагыштырганны ишетәм икән, бу хакта онытырга тырышам!

ХОККЕЙ

Тимур Билалов

Дмитрий Воронков

СНОУБОРД

Милена Быкова

Владислав Хадарин

Вик Уайлд

ФИГУРАЛЫ ШУУ

Евгения Тарасова

ЧАҢГЫ УЗЫШЫ

Христина Мацокина

ТРАМПЛИННАН СИКЕРҮ

Данил Садриев

ТӨП КӨНДӘШ – ВИРУС

Барыбер уздыралар! Мәгълүм хәлләр аркасында каршы чыгучылар күп булса да, Пекинда Кышкы Олимпиада ярышлары башланды. Ачылу тантанасы җомгага билгеләнгән. Спортчыларга көндәшләре белән ярышу гына түгел, коронавируска каршы да торырга туры килә. «Катнашу – үзе җиңү» гыйбарәсе бик килешеп тора быелгы Уеннарга.

Кышкы Олимпия Уеннарына Россиядән барачак командага 212 спортчы кергән иде. Әмма саннар үзгәреп тора. Вирус әләктерүчеләр дә юк түгел. Бәйрәм кайгысы юк, спортчыларга аеруча сак булырга, әле ярышка чыкканчы ук сәламәтлек өчен көрәшергә туры килә. Татарстаннан Пекинга 8 спортчы юл тотты. Моннан 4 ел элек республикадан Пхенчханга 5 кеше барган иде. Алар 4 медаль отты. Бу юлы да буш кул белән кайтмаслар дигән өмет бар.

НХЛ ярдәм итте

Узган ел ахырында Россия Олимпия комитеты Пекинга барасы 599 кандидатны атады. Араларында 119 хоккейчы булып, ул вакытта исемлеккә «Ак барс»тан 9 кешене керттеләр. Ахыр чиктә Казан клубы Кытайга 2 егетне җибәрде. Хәер, бөтенләй дә булмаска мөмкин иде. Әмма океан артындагы НХЛ түрәләре үз хоккейчыларын Олимпиадада уйнатудан баш тарткач, Россия командасын КХЛдагы егетләрдән тупларга туры килде. Шулай итеп, Кытайда капкачы Тимур Билалов белән һөҗүмче Дмитрий Воронков Татарстан спортының вәкиле булып саналачак. Тимур – тумышы белән Түбән Камадан, Әлмәттәге «Нефтяник» командасында чыгыш ясады. Рига «Динамо»сында уйнап кайтты, соңгы ике елда «Ак барс»ның төп капкачысы. Дмитрий – Ангарскида туып-үскән, әмма Казан хоккеенда тәрбияләнгән егет. Яшь булуына карамастан, «Ак барс»ның төп уенчыларыннан санала. Хоккейчылардан медаль өмет итәләр. Хәтерләсәгез, Россия командасы 4 ел элек Пхенчханда алтын яулаган иде. Быел да шуны көтәләр. Безнекеләргә үзләренә артык ышану гына комачау итәргә мөмкин.

Тәҗрибә бар

Пекиннан медаль алып кайту ихтималы зур булган спортчылар исемлегендә Казан кызы Евгения Тарасова да бар. Ул әле гыйнвар уртасында гына Владимир Морозов белән Европа чемпионатында парлы шууда икенче урынны алды. Алар Пхенчханда узган Олимпия Уеннарында да көмеш медаль иясе булды.

4 ел элек безнекеләр Көньяк Кореядән алып кайткан 4 медальнең 3есен чаңгычылар откан иде. Бу юлы Олимпиадага бездән бер генә чаңгычы бара. Христина Мацокинага – 23 яшь. Тумышы белән ул – Магадан өлкәсеннән, хәзер Татарстан данын яклый. Сүз уңаеннан, Россиянең Чаңгы узышлары федерациясе президенты Елена Вяльбеның якташы.

Татарстаннан берьюлы өч спортчы – Милена Быкова, Виктор Вайлд һәм Владислав Хадарин сноуборд ярышларында чыгыш ясаячак. Милена Быкованың Олимпиадага беренче генә баруы түгел. Тәҗрибәсе дә, димәк, уңышка ирешү мөмкинлеге дә артты. АКШта туып-үскән, хәзер Россия данын яклаучы Виктор Уайлд исә 2014 елда Сочида чемпион булып танылган иде. Дөрес, соңгы елларда ул медальләр белән сөендерә алмады. 2019 елдан Татарстан спортчысы булып саналган Уайлдның тәҗрибәсе зур. Сноубордта исә төрле хәлләр булырга мөмкин. Чаңгы белән трамплиннан сикерү ярышларына Лениногорскидан 25 яшьлек Данил Садриев әзерләнә.

Кызларга өмет зур

Олимпиадага киткән якташларыбыз моның белән генә бетми. Әмма алар башка төбәк спортчылары булып санала. Хоккей буенча ир-егетләр командасында Дамир Шәрипҗанов белән Артур Каюмов та уйнаячак. Дамир – Түбән Кама егете. Берничә сезон дәвамында «Нефтехимик»та уйнагач, ике ел элек «Авангард»ка күчте һәм былтыр Омск командасы белән Гагарин Кубогын яулады. Артур – тумышы белән Бөгелмәдән. Хәзер ул Ярославльнең «Локомотив» командасында чыгыш ясый.

Хатын-кызларның хоккей командасы белән бозга Кукмара кызы Фәнүзә Кадыйрова һәм Әлмәттә туып-үскән Ольга Сосиан да чыгар дип өметләнәбез. Фәнүзә Санкт-Петербургның «Динамо-Нева» командасында чыгыш ясый. Ольга – Уфаның «Агыйдел» клубы хоккейчысы. Җыелма команданың запас уенчылары исемлегендә Актаныштан Лиана Ганиева («Динамо-Нева») да бар.

Бары тик алтын!

Олимпиадада татар егете, Самараның Камышлы районында туып-үскән Эдуард Латыйпов та чыгыш ясаячак. Россиянең биатлон командасының лидерына әверелгән милләттәшебез күптән түгел коронавирус йоктырды. Әмма, савыгып, Пекинга китәр алдыннан Дөнья Кубогында берничә ярышта чыгыш ясарга өлгерде. «Әлбәттә, коронавирус аркасында Олимпия Уеннарына бармау куркынычы бар иде, әмма бу хакта уйламаска тырыштым. Яхшыга өметләндем, әзерлекне дәвам иттем. Хәзер инде ярыш башланганны көтәбез. Төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Барыбыз да сәламәт булырбыз һәм ярышны уңышлы чыгарырбыз дип өметләнәм», – диде ул «Матч-ТВ» каналы эфирында.

Спорттагы тәүге адымнарын Казан бозында ясаган Камилә Вәлиева исә Олимпиадада чыгыш ясаячак Россия спортчылары арасында иң популяр кешегә әверелде. 15 яшендә! Моннан 4 ел элек Пхенчханда безнекеләр откан ике алтынның берсен Алинә Заһитова яулаган иде. Камилә Вәлиевага өметләр тагын да зуррак. Башкача була да алмый! Гран-при этапларында, Россия һәм Европа чемпионатларында рекорд артыннан рекорд яңарткан кызчык фигуралы шууда дөнья лидерына әверелде. Мәскәүдә яшәүче татар кызыннан бары җиңү генә өмет итәләр.

Сан

- Олимпия Уеннарында алтын медаль яулаган спортчыга Россия Хөкүмәте **4** миллион сум күләмендә акча түләячәк. Көмеш медаль ияләре – **2,5** миллион сум, ә бронза отучылар **1,7** миллион сум күләмендә премия алачак. Моннан тыш, уңышка ирешкән спортчыларны төбәкләр һәм иганәчеләр дә игътибарсыз калдырмый.
- АКШның Gracenote аналитика оешмасы белгечләре ясаган фаразларга ышансаң, Россия спортчылары Пекинда **10** алтын, **12** көмеш, **8** бронза – барлыгы **30** медаль яулаячак. Россиянең Олимпия комитеты башлыгы Станислав Поздняков та якынча **30** медаль һәм командалар арасында өченче урынга өметләнә. **2018** елда Пхенчханда Россия спортчылары **17** медаль (**2**+**6**+**9**) отты.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

СЫНАУ АША КИЛГӘН БӘХЕТ

«Исән калсам, башкаларга ярдәм итәр идем». Зәй шәһәрендә гомер итүче Мария Костюченко үз-үзенә әнә шулай дип сүз бирә. Гомеренең иң матур чорында, 36 яшендә урын өстенә кала ул. Йөгереп эшләп йөргән ханым бер атна эчендә авыруга сабыша. Шөкер, язмыш ничек кенә сынаса да, ул үз дигәненә ирешә, балалары хакына аякка баса.

Күрәчәк йөртә

– Язмыш безне кечкенәдән сынады. Әти үлгәндә миңа өч яшь иде. Алты бала ятим калдык. Күрмәгәнебез калмады. Әтисез яшәүнең кыенлыкларын белсәгез иде. Иван исемле туганым 7 нче класста укыганда, әнигә ярдәм итәм дип, аяксыз калды. Комбайн ярдәмчесе иде, йөртүчесе күрмичә, комбайн астында кала. Абый ничек итсә итә, сикереп чыгып, үзен коткара. Бер аягы юк, икенчесе яраланган. Йөртүчесе инде ерак киткән була. Ә абый, олы юлга чыгар өчен, басу буйлап шуыша. Әнә шул чакта икенче аягы да өзелеп кала, – дип сөйли Мария ханым. – Абыем биреште. Дәваланып кайтканнан соң, укуын дәвам итте. Үзе агачтан протез ясап киде. Абый гарипләнгәч, безнең тормыш тагын да авырлашты. Бар өмет әниемнең беренче никахтан туган кызында иде. Гөлфәния апа безне ачлыктан коткарды да инде.

Үзбәкстанга киткән Гөлфәнияләре эшкә урнашкач, әнисе белән туганнарын үз янына чакыра. Евдокия түти, биш баласын ияртеп, юлга чыга. Тормышларын рәтләр өчен, мамык җыялар, нинди эш булса, шуны эшлиләр. Хезмәтләренә акча ала башлагач, алар хәлләнеп китә. Берничә елдан Евдокия түти, балаларын алып, кайтыр юлга чыга. Туган якның һавасы да башка шул аның! Үз ягына кайткач, тормыш тагын көйләнә.

Аксубай – Зәй арасы

Евдокия түтинең балачагы авыр була. Әниләре иртә үлә, әтисе икенче хатынга өйләнеп, балаларын алып, Себергә чыгып китә. Шуңа да Евдокиягә тиз үсәргә туры килә. 9 яшендә инде ул кешегә ялланып бала карый. 16 яшендә ашханәдә савыт-саба юа башлый. Әнә шунда ашарга кергән бер егетнең татарча эндәшүе сискәндереп җибәрә аны. Аксубайныкы икән. Алар дуслашып китә, аннан араларында мәхәббәт кабына. Яшьләр никах укыта. Евдокиягә Зәйтүнә дип исем кушалар. Күп тә үтми, фин сугышы башлана. Ире сугышта хәбәрсез югала. Кулындагы кечкенә Гөлфәниясе белән Евдокия түти туган ягына кайтып китә. Зәйдә Филипп белән таныша.

– Әти үлгәч, әни ялгыз яшәде. Беренче ирен дә сагына иде. Әтине дә. Без гомер буе, Гөлфәния апаның туганнарын табарга иде, дип яшәдек. Алар үзләре дә аны Ильясова Гөлфәния дип эзләгәннәр. Тик апаның кияүгә чыккач, фамилиясе үзгәргән иде. Әнә шуңа да табыша алмаганнар, – дип сөйли Мария ханым. – Насыйп булгач, табыштык без. Зәйдә бер туйда идек. Шунда бер егет сыздырып гармун уйный. Туганнан туган апам бу егетнең кайсы яктан икәнлеге белән кызыксынды. Аксубай районы Кыязлы авылыныкы икән. Шул гармунчы аша Ильясов фамилияле кешеләргә хат язып җибәрдем. Өч көннән бер автобус кеше килеп төшмәсенме? Телеграмма сугып, апаны ялга чакыртып кайтардык. Аннары инде бер автобус булып, без аларга бардык. Шул кешеләр белән гомер буена дус-тату, аралашып яшәдек. Әниебезнең кабере дә шул авылда.

Язмыш дими, ни диясең, әниләре 87 яшендә кияүгә чыга аларның. Ул вакытта инде Евдокия түти әле бер, әле икенче баласында яши торган була.

– Әнинең Түбән Камада торган чагы иде. Апага үпкәләгәнме, авылны сагынуы булганмы инде, елап утыра икән. Ә каршы йортта исә бер бабай шулай ук балаларында кунак булып йөри икән. Аныкылар унбер! Бабайның да үз өенә кайтасы килә. Кызына болай ди бу: «Хәзер урамга чыгам да, кем очрый, шуңа өйләнәм». Безнең әнигә юлыга. Бабай артыгын сөйләшми, кияүгә чык миңа, ди дә әнине алып кайтып китә. Мин әле ул чакта бераз читенсенеп тә йөрдем. «Шул яшьтә нинди кияү инде?!» – дим, – дип сөйли Мария ханым. – Әни, бабайга ияреп, Аксубай районы Кыязлы авылына кайтып төшкән. Җырчы Фирдүс Тямаевның бабасы булып чыкты ул. Әни үзе дә белмичә, олыгайган көнендә беренче иренең авылына кайтты. Шакир абый белән ул 8 ел бәхетле яшәде. Ятып авырмады, гел хәрәкәттә иде, камыр ризыклары пешерде. Үләр алдыннан да алты көн генә авырды. Шакир абыйның теләгенә каршы килмәдек: әнине мөселманча итеп беренче иренең туганнары янәшәсенә җирләдек.

«Мине саклады, ә мин – юк»

Күңеленә авыр булса да, Мария ханымның үз язмышын да сорамый булмады. Үзенең исән булуы өчен иренә рәхмәт укый. Ул мине саклады, мин аны саклый алмадым, ди.

– 36 яшемдә кинәт авырый башладым. Кулыма нәрсә тотсам, шул әйбер төшеп ватыла. Дүрт көн рәттән, шифа эзләп, хастаханәгә терапевт янына бардым. Алар берни әйтә алмый, чиремне тапмыйлар. Бишенче көнне невропологка җибәрделәр. Мин чиратта утырганда йоклап киткәнмен. Табибның битемне чәбәкләвенә уянып киттем. Кичекмәстән мине Казанга җибәрде, – ди Мария Костюченко.

Хәле җиңел булмый. Баш капкачын ачып, шеш алалар. Аны алганда күз нервына зыян килә. Мария ханым бер ай бик авыр хәлдә була. Шул чакта ире Геннадий янынннан да китми. Хатынын сабый баладай тәрбияли. Хастаханәдән чыккач, Мария ханымның ике күзе дә эчкә бата. Начар күрә башлый. Тагын ике ел урын өстендә үтә. Әниләре авыргач, балалары да тиз үсә аларның. Өйне тәртиптә тоту, ашарга әзерләү, малларны карау аларга күчә. Әкренләп Мария ханымга хәл керә. Башта сул як күзе уңайлана, аннары – икенчесе. Әкренләп күрә башлый. Урыннан торгач, ул үзе кебек начар күрүчеләргә ярдәм итә башлый. Аны районның сукырлар оешмасы җитәкчесе итеп куялар. Урын өстендә яту тормышның кадерен белергә өйрәтә. Мария ханым дөньяны тагын да яратып яши башлый. Кызганыч, ире генә озын гомерле булмый. Моннан 11 ел элек үпкәсендә яман шеш табалар да, ике ай эчендә вафат була.

– Әнә шулай минем өчен күпме тырышты да, бер көн дә авырып карамаган килеш, кинәт кенә урынга егылды. Ул мине коткарды, ә мин булыша алмадым, – ди Мария ханым. – Балаларымның игелеген күреп яшим хәзер. Тормышны бик яратам. Гел матур киенергә тырышам. 65 яшь әле ул – картлыкның яшьлеге башланган чак. Гомерем буе биек үкчәле аяк киеме кидем. Әле дә туфлине салган юк. Ходай сынады да, рәхмәтен дә бирде. Көчле булырга өйрәтте. Ә мин шуның белән бәхетле.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Җылыту

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Кыш уртасында дәвамлы суыклар булачак, дигән идем. Әмма бу фаразлар чынга ашмады. Чын кышкы салкыннар әле дә күренми. Быел хәтта хач мәну көннәрендә дә салкын булмады – җепшек кар яуды. Бөтен суык язга калачак дигән сүз бу», – ди Әмир абый. Февраль, нигездә, җылы булачак. «Халык синоптигы» зәмһәрир суыклар февраль ахырында башланып, март уртасына кадәр дәвам итәр дип фаразлый. «Көннәр яз башында гына суытып калса ярый да. Табигатьнең кар эреп беткәч салкыннар белән куркыта торган гадәте бар. Шунысы куркыныч. Анысы уҗымнар өчен хәтәр», – ди Әмир Шәрәфиев. Яз исә вакытында килер дип фаразлый ул.

КФУның Метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев сүзләренә караганда, соңгы берничә елда Татарстандагы һава торышына төньяк-атлантик циклон йогынтысы ясый. Шуның нәтиҗәсендә уртача һава температурасы күтәрелә, явым-төшем арта бара. «Февраль аенда Татарстанда уртача 13 градус салкын булырга тиеш иде. Әмма ул 4–5 градустан да түбән төшмәде. Ял көннәрендә республикада айлык норманың өчтән бере күләмендә кар явачак. Юллардан болай да йөрерлек түгел иде. Хәзер бөтенләй мәхшәр булачак», – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда.

Глобаль җылыну аркасында бөтен Җир шары күләмендә табигать бәла-казалары да ешрак күзәтелә башлаган. КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институты метеорология, климатология һәм экология кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев китергән саннардан аңлашылганча, Россиядә уртача һава температурасы ун ел саен – 1,5 градуска, Җир шары күләмендә 0,2 градуска арта бара. «Глобаль җылыну тизлегеннән дә ике тапкыр күбрәк бу», – ди белгеч. Шул сәбәпле җир йөзендә давыл, җил, өермә кебек табигать бәла-казаларының да артуын искәртте. Җәй көне күзәтелгән чамадан тыш эсселәрне дә шушы глобаль җылыну белән бәйләп аңлата белгеч.

– Быелгы кыш бик үзенчәлекле. Кар катламы бик калын, явым-төшем явып кына тора. Тычканнар белән тукланучы ябалакларга быел аеруча кыенга туры килде. Карга чумып, шунда төн кунучы бөҗыр, көртлек, суерларга мондый карлы кыш, киресенчә, файдага гына булды. Бүген кар катламының биеклеге 60 сантиметрга җитә. Моңа кадәр кар катламы 10 сантиметрдан артмаган кышлар да булды бит», – ди Юрий Переведенцев. Кошлар димәктән, быел Татарстанда карабүрекләр дә бик сирәк күзәтелгән.

Моның кадәр кар кайчан эреп бетәр икән соң? Синоптиклар анысын да фаразлаган инде. Кар апрельнең икенче ункөнлегендә яхшы ук эри башлар дип көтә алар. «Мартта кар катламы әлләни үзгәреш кичермәячәк әле. Яз башы саналса да, кышның дәвамы да булып тора ул. Язгы җылы көннәр елдагыча 31 март – 3 апрель тирәләрендә башланыр дип көтәбез», – ди Юрий Переведенцев.

Сүз уңаеннан, Казан гыйнварда иң күп кар чистарту кораллары сатылган Россия шәһәрләренең беренче унлыгына кергән. «AliExpress» оешмасы белгечләре уздырган тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, кыш уртасында илдә кар чистарту коралларына сорау, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, сигез тапкыр арткан. Иң күп эш коралы Мәскәү, Краснодар, Санкт-Петербург шәһәрләрендә сатылган. Казан әлеге рейтингта – тугызынчы.

ФЕВРАЛЬ АЕНА ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ

✓ Февральдә каен ботагында карлар алка-алка булып асылынып торса, ул елда иген уңар.

✓ Февральнең беренче атнасында тотрыклы һава торышы сакланса, җәй озын, яңгырлы булыр.

✓ Февральдә бәс күп булса, агач җимешләре уңар, бал күп булыр.

✓ Февраль ае ахырында кар күп яуса, борчак белән чикләвек уңар.

✓ Әгәр кышның бу ае буранлы икән, августта яңгыр көт, уҗым игене уңачак.

✓ Кар күп ятса, үлән калын булачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ВАФИРӘ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНАНЫҢ КЫЗЫ КАМИЛӘ:

«ӘНИ ҮЗ ЧОРЫНЫҢ ДАВЫЛЫ ИДЕ»

Әнисе сәхнә мөнбәрен сайласа, кызы балаларга музыка белеме бирүне үз иткән. Россиянең атказанган, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисты Вафирә Гыйззәтуллина кызы Камилә турында сүзебез. Төс-кыяфәте белән дә, холкы белән дә әнисен хәтерләтә ул. Камилә белән танылган җырчының иҗаты һәм шәхесен танытуга бәйле проблемалар хакында сөйләштек.

:: Камилә, Казанда әниегез Вафирә Гыйззәтуллинага бәйле урыннар күпме?

– Андый урыннар бик күп. Алар арасында күңелгә иң якыны – яшәгән йорты һәм Казанның Вахитов районындагы 5 нче лицей каршында Вафирә Гыйззәтуллина исемен йөрткән 26 нчы музыка мәктәбе. Быел депутат Олег Морозов ярдәме белән йортыбыз диварына мемориаль такта куелды. Бу гозер белән мин 11 ел йөрдем, ул арада күпме министр алмашынды, күпме кәгазь тутырылды, күпме сүз сөйләнде, эш кенә эшләнмәде. Күрәсең, әнинең 75 еллыгында сәгате сугарга тиеш булгандыр. Узган елның 16 сентябрендә, аның вафат булган көнендә, мемориаль такта ачылды.

Икенче зур эшем – әнинең кабер ташын яңарттым, өр-яңа чардуган кордырттым. Бусын үз көчем белән башкарып чыктым, шөкер. Шуңа күрә авыз тутырып әйтә алам: мин бәхетле. Нинди зур эшләр башкарылды бит.

:: Вафирә Гыйззәтуллина исеме ничек мәңгеләштерелә?

– Исәнлегем булганда, кулдан килгәннең барысын да эшлим. Вафирә Гыйззәтуллина исемендәге фестиваль оештырабыз. Ел саен 26 нчы мәктәптә 1а музыкаль сыйныф балалары белән Вафирә Гыйззәтуллинага багышланган ачык дәрес үткәрәбез. Әйткәнемчә, 26 нчы музыка мәктәбе әни исемен йөртә, биредә балалар аның репертуарын да өйрәнә. Бер караганда, кечкенә эшләрдер, ләкин күпмедер бала күңеленә Вафирә Гыйззәтуллина турында мәгълүмат сеңә бит.

Бу мәктәпкә әнинең исемен бирү – лицей директоры урынбасары Екатерина Козлова идеясе. Ул шулкадәр әнинең иҗатын олылады: безнең күңелләр аваздаш, дип әйтә иде. Аның җиңел кулы белән лицейда Вафирә Гыйззәтуллина музее да оешты. Тагын бик күп идеяләребез бар иде, узган елны 46 яшендә кинәт вафат булды... Искә алуыбыз рухын шат кылсын иде инде.

Мине иң дулкынландырганы – яшьләр күңелендә әнинең образы, аның моңы яшәве. Алай булмаса, иҗатларында әни рухы калкып чыкмас иде. Әйтик, талантлы рәссам Руслан Ибраһимов әнинең портретын ясады. Ул шулкадәр камил, шулкадәр оста... Улым Камил аны сатып алды һәм миңа бүләк итте. Мин исә аны мәктәпкә элдем. Чит илдән килгән кунаклар да әлеге картинага шаккатып китә. Үзем әнигә багышланган «Аура любви» дигән телефильмны бик яратам. Тагын «Вафирә» дигән фильм төшерделәр. Менделеевскидан якташы, укытучы Рәмзия Мөхетдинова «Бөркет йөрәкле былбыл» дигән китап чыгарды.

:: Талантлы яшьләр күңелендә хөр күңелле җырчы яши, алар аны иҗат итәләр. Руслан Ибраһимовны әйтүем, ә бит тулы бер чор алмашынды, хәзерге яшьләрнең күбесе Вафирә апаның протест йөзеннән майданда РСФСРның атказанган артисты таныклыгын яндыруын да, аның халык алдында кыю чыгышлар ясавын да, фаҗигасен дә белми...

– Вакыт узган саен шәхесләр турында хәтер тоныклана. Әмма алар барыбер яңадан әйләнеп кайта. Әни оныталыр дип уйламыйм мин. Кыска гына гомерендә нинди бай мирас калдырды бит. Дөрес, әлеге мирас радиотелевидениедән яңгырап торса, яхшы булыр иде дә... Замана башка, музыка да, зәвык та бүтән төрле.

> Әни җырчы гына түгел, ул шәхес, әйдәман, үз чорының давылы иде. Татар егетләрен «кайнар нокта»га җибәрүгә каршы чыгып, Камал театры алдында үзенең РСФСРның атказанган артисты таныклыгын яндырды. Моның белән ата-аналарны кызганып, бу сугышка карата үз катгый карашын белгертте. Андый шәхесләр бүтән юктыр ул.

Нәҗип Җиһанов аның опера театрында җырлавын теләде, ул исә эстраданы сайлады. Опера театрында бер генә ел эшләде. Халык алдында исә җырлап кына калмый, алар алдында чыгышлар ясый, милли үзаңны

Камилә Гыйззәтуллинаның шәхси архивыннан

уятырга тырыша иде. Авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә йөрде. Кызык хәлләр дә булгалады. Авыл халкы әнине тын да алмыйча тыңлый иде. Бер клубта әни: «Керим әле урманнарга...» – дип җырлый. Бер әби шунда: «И балам, анда кереп, ни бар инде, анда керсәң, чыгасы була бит...» – дип, әни белән сөйләшә башламасынмы!.. Ничек итсәм иттем, җырлап бетердем, дип искә ала да көлә иде әни. Авыл халкы ихлас бит ул, самими. Концерттан соң: «Кызым, син җырлап кына йөрисеңме соң?» – дип кызыксынучылар да булгалый. Әни: «Юк, идән дә юам әле мин», – дип җавап бирә. Чыннан да, Әухәдиев көллиятендә идән юды ул. Шундый авыр вакытларны да горур үткәрә белде. Ул чорның шәхесләре шундый иде алар.

Безнең өйгә кичләрен кемнәр генә җыелмый иде. Композиторлар, язучылар, шагыйрьләр. Рәшит Ахунов, Туфан Миңнуллин, Сибгат Хәким, Фасил Әхмәт, Заһид Хәбибуллин... Хәмдүнә апа да килә иде. Берзаман кеч-кенә Камил елый да елый. Хәмдүнә апа мендәргә салды да, өстәлгә куеп, тирбәтеп йоклатты. Хәзер берсе дә исән түгел инде...

:: Әниегезнең туган көне гадәттә ничек үтә?

– Соңгы елларда әнинең туган ягы – Менделеевск районында үтә. Исән чакта әни районда оештырыла торган «Соловушка» бәйгесенең жюри рәисе булган. Хәзер әлеге эшне мин башкарам. Быел да 12 февральдә Менделеевскида булам. Туган авылы Камайда да булырмын, догалар кылырмын...

Туган ягы белән элемтә ныклыгына күңелем сөенә. Берәгәйле итеп эшлик, матур килеп чыксын дим, бик тырышалар. Әнием гомере буе матурлыкны яратты.

:: Хәзерге заманда яшәсә, Вафирә апа ни әйтер иде икән?

– Бу – аның заманы түгел, яши алмас иде, мөгаен. Якын кешеләре – Туфан Миңнуллин, Фасил Әхмәт һәм бик күп шәхесләргә хәзерге заманда яшәү авыр булыр иде. Хәмдүнә апа булып, ул да бит китеп барды...

:: Хәзер ретро җырларны яңача башкару модада. Музыка белгече буларак моңа ничек карыйсыз?

– Ике яклы мәсьәлә бу. Иң мөһиме: заманча җырда һәм заманчалаштырылган җырда эчтәлек булсын, мәгънә югалмасын. Мин бу җәһәттән Алла Пугачеваны үрнәк итеп куям. Җырлары һәр дәвердә заманча һәм хит булды. Әни дә ярата иде аны. Эстониядә гастрольдә чакта без Алла Пугачеваның концертында да булдык. 1979 ел иде ул. Толкунова, Зыкина, Маврыкиналар белән аралашты. Бик истәлекле сәфәр булды ул. Миңа ул чакта 9 яшь кенә булса да, барысын да хәтерлим. Нәҗип Җиһанов та балачактан күңелгә якын кеше булып кереп калган. Хәзер дә, музеена барам әле, Нәҗип абыйга яңалыкларны сөйләп кайтам, дип йөрим.

:: Әниегезнең кайсы җыры күңелегезгә аеруча якын?

– Резедә Әхиярова көен язган «Юатма» җыры. «Горурлыгын сакламаса кеше, язмышы да куяр борылып» дигән сүзләре бигрәк якын.

:: Әниегез төшләрегезгә керәме?

– Хәзер юк инде. Мин аның туган һәм вафат булган көннәрендә «Мәрҗани» мәчетендә дога кылдырам. Үзем һәр көнне эшкә барганда-кайтканда, кичен догалар укыйм. Заманында Рәшидә абыстайдан дин сабаклары алган идем. Шулай гына күңелемә тынычлык таптым.

:: Исемегезне Ларисадан Камиләгә, Джураева фамилиясеннән Гыйззәтуллинага күчкәнгә әтиегез үпкәләмәдеме? Ул да – сәнгать кешесе, аның белән аралашасызмы?

– Юк, үпкәләмәде. Камилә исемен алганда миңа 25 яшь иде, мулла азан әйтеп, исем кушты. Гыйззәтуллина фамилиясенә әни белән яшәгәнгә күчтем. Әти белән хәзер бик яхшы аралашабыз. Аның да истәлекләре шактый, шуларны яратып тыңлыйм. Әти 86 яшенә кадәр «Юность» мәдәният сараенда «Кичке утлар» хорын җитәкләде.

:: Улыгыз Камил татарча беләме?

– Әлбәттә! Ул татар гимназиясен тәмамлады. Миңа, кызганыч, андый бәхет тәтемәде. Үзлегемнән, татарча китаплар укый-укый өйрәндем. Сезнең белән беренче интервью ярым урысча узган иде.

:: Хәзер татарча аралашабыз!

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Блиц-сораштыру

– Иң зур теләк?

– Әни төннәр буе көндәлекләр яза иде. Анда шигырьләр дә, истәлекләр дә, тарихка, чорга караш та бар. Анда – аның гомере, күргәннәре, аралашкан кешеләре. Шуны туплап, китап итеп чыгарырга иде. Вафирә Гыйззәтуллинага багышланган саллы басма чыгуын телим.

– Казан ул – ...

– күңелгә якын шәһәрем. Әни, Казанны яратмыйм, дип әйтә иде. Казанны түгел, ул чордагы мохитне, вазгыятьне яратмагандыр ул. Җаны тарсынгандыр.

– Иң зур байлык – нәрсә ул?

– Кешеләрнең рухи байлыгы, мәрхәмәтлелек.

– Еш кабатлый торган фраза?

– Матурлык дөньяны коткара. Әчке матурлык турында әйтүем.

РАВИЛӘ ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ

ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН

(БӘЯН)

< Дәвамы. Башы 2021 елның 10 декабрь, быелның 21, 28 гыйнвар саннарында

***

Сәет укуда тиз алдырып китте. Ул укытучысы сөйләгәнне бик тиз отып ала. Өйдәге эшләрен дә бабасы әйткәнче үк эшләп куя. Мәктәп киемнәрен саклап кына кия. Сыерны көтүгә куу, бозау арканлау, бәрәннәргә үлән алып кайту, су ташу – барысы да үзеннән-үзе Сәет өстенә күчте. Авыру бабасы күбрәк намазлык өстендә утыра. Аның моңлы итеп Коръән укуы Сәетнең җанына иңә барды. «Өйрән, улым, – диде бабасы, – дога әниеңә ризык булып бара. Укымышлы, динле бала калдырган ата-ананың тәне мәңге тәмуг күрмәс. Алар теге дөньяда – фирдәвес җәннәтләренә эләгеп, зәм-зәм сулары эчеп, зиннәтле сарайларда гына яшәрләр, – ди. – Әниең дөньялыкта рәхәт күрмәде, улым. Инде менә син Коръән укысаң, әниең тегендә рәхәттә яшәр. Өйрән, улым. Тик бу турыда кешегә сөйли күрмә. Минем хакта да, бабай Коръән укый, дип әйтмә. Алла сакласын, алып китеп ябып куярлар. Үзең генә калырсың. Ул мәлгунь бригадир атаңнан өмет юк. Аның атасы да дөньяның бер явызы иде. И улым, мәчет манарасын кисәргә шул бәдбәхет менде инде. Гөрселдәп килеп төште җиргә мәчет манарасы, уфылдап. Бөтен авыл халкы җыелды. И җыладылар инде, бигрәк тә хатын-кызлар җылады. «Мәңгегә рәхәт күрмә, кабахәт. Нәселең киселсен, үлә алмый интегеп ят»,

– Әй бабай, Каракай әби әйтте: «Әниеңнең җаны күбәләк булып очты», – диде. Ә күбәләкләр кыш көне йоклый.

– Юк, улым, әниеңнең җаны төрле кыяфәттә кайта: күбәләк булып та, Ай нурлары булып та. Тәрәзәдән үрелеп карый әле ул сиңа. Минем улым ничек яши икән дип. Тәртипсез түгел микән дип. Әниеңне борчыма, улым, җәме.

– Ярар, бабай, борчымам. Ул Рәфыйк мине гел үчекли. Ятим, хәерче, ди. Бабай, без хәерче түгел бит, име?

– Түгел, улым, Ходай иман байлыгын бирсен. Дөнья малы – дуңгыз каны ул, балам. Бер дә аптырама, җәме? Син аның ише малайлардан читтә йөр.

– Ярар, бабай, – диде Сәет, дуңгызның начар нәрсә икәнен аңлап. Ә үзе Рәфыйкны кыл дуңгыз кыяфәтендә күз алдына китерде дә эчтән генә елмаеп куйды. Бабасына ияреп Теләчегә барганда, дуңгызлар күреп шаккаткан иде малай.

– Сыерыбыз бозаулады син җүгында. Бикәч бозау китергән. Өйгә керттем сыерны имезергә. Кышы бигрәк суык. Җылы мал абзары булмагач, туңар, дидем.

Сәет өйгә атылды. Анда сыер апаралы салам ашый, ә кечкенә генә, хәлсез генә бозау сыер имиенә танавын төрткән. Ай-һай, матур бу Чувашның бозавы! Үзе җирән булса да, бозавы аклы-каралы. Сыерга, чуваш кешесеннән сатып алганга, «Чуваш» дип исем кушканнар иде.

– Бабай, ник аклы-каралы ул бозау, Чуваш үзе җирән бит?

– дип теләделәр. Аллаһы Тәгалә күрә ул, җәзасын алмый калмас. Манараны кискәндә, мәчетнең ае бер кырыйга тәгәрәде. Мин, улым, ул айны тиз генә чабуыма алып тыктым. Берәү дә күрми калды. Печәнлеккә яшердем мин аны. Күрсәтермен әле. Гомерем күп калмагандыр. Инде син аякка басканчы яши алсам ярар. Килер бер көн, балам, сез яңа мәчетләр салырсыз. Дин барыбер кайта ул. Аллага ышанмыйча мөртәт булып күп яшәп булмый. Дөрес түгел бу. Син, улым, ул айны яңа мәчетнең манарасына куярсың, яме. Бу – минем васыятем, улым. Дөньялыкны белеп булмый.

– Ярар, бабай, – диде оныгы.

Сәетнең әнисен ахирәттә рәхәт яшәтәсе килә иде. Ул бик тырышып Коръән укырга өйрәнде. Тавышы моңлы иде малайның. Кичләрен җиделе лампаның сүрән уты яктысында сәкедә аякларын бөкләп Коръән укучы оныгын тыңлап, карт рәхәтлектә йөзде. Күзләреннән яшьләре агып төшә иде. Аллага шөкер, иманлы балам кала, дип юанды карт. Әтисе кебек явыз бәндәләр оныгының рухын сындырмасыннар иде инде. Йә Раббым, шушы ятим хакына гомер бир, дип теләде ул.

– Әйдә, улым, ятыйк, иртәгә иртүк торасы бар. Сыер да бозауларга тора. Инде бик авырайган, Алла сакласын. Бозавы туңып үлә күрмәсен. Исән-имин булса, көзгә сиңа киемнәр алырга акча юнәтеп булмасмы дип, карт бер кулы белән куыкны каплап, өреп, лампаны сүндерде. Лампаның уты дерт-дерт итеп торды да өйгә керосин исе таратып сүнде. Өй караңгылыкка чумды. Мич астындагы чикерткә генә сайравыннан туктамады. Тышта салкын. Ап-аяз төн. Бабасы, бисмилласын әйтеп, ухылдап, сәкегә менеп ятты. Яткач та, әле бик озак медер-медер дога укыды. «Төне бигрәк аяз, ай яктысында мәрҗән тезәрлек, сөбханалла», – диде карт, сөенеп.

Сәетнең күзенә йокы кермәде. Бабасы көзгә киемнәр алабыз диде бит. И-и, ничек әйбәт булыр иде, Рәфыйкныкы шикелле матур форма, сумка алсалар. Ату ул һаман Сәетне үчекләргә генә тора. Беркөнне мәктәптән кайтканда, фанер сумкасын тибеп очырды.

«Хәерче тәре, сумка алырга да акчагыз юкмыни? Бабаң алып бирә алмыймы, класста син иң хәерче, сине атаң да ташлап киткән. Ул мине ярата. Нурания апа да сине җәлләп кенә мактый. Ә син шуңа ышанасың. Дөм ятим бит син», – дип, елый-елый карга сибелгән китап-дәфтәрләрен җыеп азапланган Сәеткә кителеп типте явыз малай. Сәетнең сыны катты. Сәет, бөтен көчен җыеп, Рәфыйкка ташланды. Кара савыты ватылып, карасы түгелде. Ике малай мышный-мышный карда аунадылар. Әле берсе, әле икенчесе өскә чыкты. Кара савытының ватылган пыяласы Рәфыйкның битенә кадалып, кар өстенә кып-кызыл кан ага башлады. Малай, бияләе белән ярасын каплап, акырып елап, өенә чапты. Эчендә ачу кайнаган Сәет, җиңү шатлыгы кичерсә дә, кан күргәч курыкты. Бабасы ни әйтер?

Ул кайтканда, бабасы капка төбен көрәп йөри иде. Канга буялган оныгын күреп, кырыс кына: «Нишләдең, ник шулай талалып кайттың?» – диде.

– Әйсәнә, Рәфыйк белән сугыштык.

– Ниткән хәл ул сугышып йөрү? Юньлелеккә илтерме ул сугышу?! Бүтән күрмим бу кыяфәтеңне. Әниең күреп тора, ни әйтер!

– Аттан ала да туа, кола да туа, балам.

– Карале, бабай, моның борыны Рәфыйкның ботинкасы төсле күн икән.

Бабай, бераз дәшмичә торганнан соң:

– И балам, нәүмизләнеп яшисең инде. Алла боерса, бозауны саткач, Теләче базарыннан синең дә аягыңа алып кайтырбыз. Исән-сау гына булсын мал, – диде.

Бабай сыерны абзарына алып чыгып китте. Бозау да, әнисе артыннан ияръсе итеп, әле ныгымаган аяклары белән алпантилпән килеп, ишеккә юнәлде. Сәет, бозауга каршы төшеп, аны кочаклап алды. Бозау дымлы һәм җылы иде. Ул кара җимештәй кара күзләре белән малайга аптырап карап торды да кытыршы теле белән аның битеннән ялап алды. Сәеткә күңелле булып китте. Өйдә тагын бер җан иясе артты.

Бабасы, кергәч, бозауны ишек төбендәге бәҗрага арканлап куйды.

– Улым, бозау хаҗәтен үти башласа, менә бу савытка турылат, – дип, мич кырыена яньчелеп беткән калай савыт китереп куйды.

...Мичтән борчак ашын чыгарып ашый башлаганда, ишектә укытучы апасының ягымлы тавышы ишетелде.

– И-и, сыерыгыз бозаулаган икән, игелекле мал булсын, – дип, гөрләп килеп керде Нурания апасы. – Кара әле, нинди матур бозау! Туны да ала-кола. Исән-сау гына үссен инде.

Сәетнең колак очларына кадәр кызарып чыкты. Ул:

– Исәнмесез, апа! – дип әйткәнен сизми дә калды.

– Без бүген исәнләшкән идек инде, Сәет. Әле менә сезнең яннан үткәндә, кереп, хәлегезне белеп чыгыйм, дидем. Нихәлләрдә ятасыз икән? Менә кичә балан бәлеше пешергән идем. Сез дә авыз итегез!

– Бик зур рәхмәт, Нурания, без ятимнәрне искә алганың өчен. Безгә хәзер балан бәлешләре күрү юк инде ул. Хәят кызым, аягында йөргәндә, шундый да тәмле итеп пешерә торганые... Үзегез нихәл торасыз соң? Өегездә татулыкмы? Татулыктыр, нәселегез нык сезнең. Затлы, игелекле нәсел. Маһруйбикә карчык исән-саумы? Һаман шулай ютәллиме? Шулай ул: чир килгәндә генә тиз килә, аннары чыбыркылап куса да китми. Әйдә, утыр. Мичкә борчак ашы куйган идем. Иллә дә изрәп пешкән инде. Борчак ашы мичтә тәмле пешә. Телеңне йотарлык булган, мин сиңа әйтим.

– Юк, Зариф абзый, мин китим инде. Әле кызымны да Миңлегөлсем әбидә генә калдырган идем. Бу арада бик елап тора. Әллә берәр җире авырта инде.

Сәет, уңайсызланып, ишегалдына чыгып китте.

– Зариф абзый, менә, ачуланмасаң, улымнан калган киемнәр бар иде. Улым быел бик үсеп китте. Әтисе шикелле, буйчан булырга охшаган. Сәеткә ярар кебек. Сумкасы да ару әле. Мин киткәч, кигезеп карарсың, яме, – дип, уңайсызланып, урыныннан торды.

Ул чыгып киткәч, Зариф карт урынында озак утырды. И-и, бу баланың игелеклелеген күр инде. Үзенең дә өч баласы бар бит. Ул да майда-балда йөзми. Балаларының авызларыннан өзеп алып килгән инде ул ризыкларын. Карт күчтәнәч-бүләкләргә озаклап дога кылды. «Балаларыңның рәхәтен күр, сау-сәламәт бул», – дип теләк теләде. Укытучы чыгып киткәч, Сәет өйгә керде.

Дәвамы бар >



Фәнис ЯРУЛЛИН

ЯКТЫ ЧЫРАЙ

Якты чырай, бары якты чырай
Кирәк була кайчак кешегә.
Барлык ачуларың онытасың,
Рәнҗүләрең бетә эчеңдә.

Якты чырай белән каршы алып,
Озатсалар барган җиреңдә —
Күк капусы ачылып киткән кебек
Бер яктылык туа күңелдә.

Әллә нинди бүләк алган сыман
Сөенечтән балкып йөрисең.
Күләгәләр кинәт юкка чыга
Дөнья ямьсезлеген күрмисең.

Алтын түгел, көмеш түгел юкса,
Якты чырай гына лабаса.
Кояш яктысы да кимер кебек,
Якты чырайлылар булмаса.

2001

ӨМЕТ СИБИК АЛАР ӨЧЕН ДӘ

Өметләрне чәчтем аланнарга
Кар өстенә кара буранда.
Бәлки, алар җиләк булып пешәр
Кышкы салкын кара урманда.

Ул җиләкне төннең уртасында
Барып җыяр ятим Үги кыз.
Бәхетеннән йөзе балкыр аның,
Күңелендә эрер калын боз.

Өметемне сиптем Зөһрә кызның
Зәңгәр чиләкләре эченә.
Чиләкләрдә кинәт су чайпалды
Керел төнге күкләр төсенә.

Шулчагында кинәт көянтәгә
Тулган Ай да кунып өлгерде.
Алып менеп китте Зөһрә кызны
Һәм гүзәл Ай кызы иттерде.

Өметемне сиптем юл читенә,
Һичбер гөл дә үсмәс җирләргә.
Мөмкин аны атлар таптарга да,
Юл тузаны мөмкин күмәргә.

Ә кем белә? Чәчәк чыгып куйса,
Юл ташларын ярып, шартлатып.
Шул чәчәккә сөенеп юлчы карар
Аруларын онытып, шаккатып.

Өметемне сиптем кара төнгә,
Балкып янмаса да һәрберсе.
Мәхәббәтен җуйган гашыйк җанга
Йолдыз булыр, бәлки, берәрсе.

Бар нәрсәсен җуйганда да кеше
Сыңар өмете калсын эчендә.
Күпләргә бит дөнья – үги ана,
Өмет сибик алар өчен дә.

2000

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Кайда сез, тараканнар?

Элек тараканнар күп иде бит. Тараканнар белән күңелле иде. Бүрәнә ярыгыннан башта ике мыек килеп чыга, аннан теге зат үзе дә күренә. Мыекларын сиңа төбәп, ашарга яраклымы-юкмы икәнеңне тикшерә дә, кул селтәп, ары китә.

Тараканнар турында тарихи язмалар калмаган. Шулай да элекке дәвердә алар кемнең кемлеген күрсәтеп торучы булган. Өеңдә таракан бар икән, димәк, ач яшәмисең, ашарыңа икмәгең бар. Тараканың юк икән – димәк, ашарыңа да юк. Таракан байлык билгесе булган. «Иртән торгач, өстәлдә йөзем җимеше дип үрелгән идем, таракан булып чыкты…» – диебрәк мактанырга яратучылар да табылган. Берәр җирдә таракан күрсәләр: «Тукта, бу безнеке түгелме соң?..» – дигән булып, ач яшәмәүләрен сиздерергә тырышканнар.

Безнең чорда аны шапшаклык билгесе дип кабул итәләр иде. Йортыңда таракан бар икән, димәк, син бик үк чиста яшәмисең. Димәк, син – пошмас кеше, югыйсә күптән аны бетерергә тырышыр идең. Шуңа күрә безнең чорда тараканга караш та башка төрлерәк иде. Үзендә таракан барлыгын яшерергә тырыша, чөнки күршесенә керсә, күршесе аңа: «Бар, ишегалдына чыгып, өс-башыңны кагып кер, тараканың иярмәсен», – дип әйтергә дә мөмкин. Болай дип әйтүче булмаса да, кайбер көнчелрәк кешеләр үзенең бер-ике баш тараканын күршегә ташлап та киткәли иде.

Мин бәләкәй чакта бездә дә бар иде. Байрак төсендә булмаса да, аны «кызыл таракан» дип йөртәләр иде. Башка төсләләре дә була, диләр иде. Мин ни өчендер башка төсләләре ак таракан була торгандыр дип уйлый идем. Алар бер-берсенә дошман була торгандыр дип. Ул вакытта «аклар», «кызыллар» белән башымны ярыйсы гына катырып өлгергәннәр булса кирәк. Һәм үзебездә «кызыллар» яшәвенә беркадәр горурланып куя идем. Эчтән генә, әлбәттә, беркемгә дә әйтмичә генә. Ак таракан да булса, барыбер, рәхәт түгел бит инде.

Тараканның артык зыяны тими иде. Үз дөньясында, үз үлчәмендә яши бит инде ул. Синекен ашап бетерми, пычратмый, тишми. Ә дәрес барганда берәрсенең китап төпләмәсеннән килеп чыкса, бәйрәм башлана. Өлкәннәр туйда да алай шаулаша алмый торгандыр. Шулай да аларга караш дошмани иде. Без дә бер кышның чатнама суыгында таракан ташладык. Бер-ике көн күршеләрдә яшәп торасың инде, өйне җылытмыйсың, анда су да, ризык та калдырмыйсың. Ашау-эчү ягы такыраеп, катып үлмәле салкынга әйләнгәч, тараканнар синең йортыңны ташлап чыгып китә. Шуны бездә «таракан ташлау» диләр. Вәт, ташладык шулай. Кызыл тараканнар юкка чыкты. Моңа сөенеп тә өлгермәдек, без ике кич кунган күршеләрнең кара тараканнары күренгәли башлады. Кием-салымгамы ияреп кайтканнар, каһәрең.

Тараканнар күчеп йөри иде. Авылныкы – шәһәргә, шәһәрнеке авылга кайта. Кием арасында да, сумка-чемоданнарда да, хәтта посылка әрҗәсендә дә сәяхәт итәләр. Һәм аларны берничек тә бетереп булмый. Совет тараканнары үлемсез иде. Заманында: «Алар хәтта атом-төш сугышыннан да исән калачак», – дип фаразлыйлар иде. Бу коры сүз генә түгел, ә Хиросимада сыналган күренеш булган икән. Шартлау урыныннан өч йөз метр ераклыкта яшәгән тараканнар исән калган. Тагын әллә нинди тәҗрибәләр үткәреп караганнар, барысы да – таракан файдасына.

Ә соңгы елларда алар юкка чыкты. Югыйсә атом сугышы да булмады кебек инде. Барысын да белүче акыллы кешеләр моны төрлечә аңлата, ә мин ризалашып баш кагып кына торам. Килешмичә булмый. Беренче сәбәп итеп, без ашаган ризыкның ясалма булуын искәртәләр. Монысын инде хәтта безнең песи дә белә. Кибеттән алып кергән ризыкларның кайсына сыртын кабарта, кайсын «күмә» башлый. Ә мин эчтән генә: «Нүжәли песиләр дә юкка чыгар?» – дип баш ватам. Икенчесе – электромагнит дулкыннар күбәю. Телевизор, суыткыч, микроволновка, телефон, интернет, вай-фай… Боларның барысы да электромагнит дулкыннар тарата. Ул дулкыннар безнең күзгә күренмәсә дә, тараканнарның мыегын кытыклата икән. Билгеле булганча, авыртуга түзеп була, кычытуга чыдап булмый. Тараканнар да шуңа чыдый алмыйча юкка чыкканнардыр.

Мин аларны кайчагында сагынып куям. Тараканнарнымы, үземнең яшьлегемнеме – аңламассың. Һәм ни өчендер алар кире кайтыр сыман тоела. Ә кайчагында алар беркая да юкка чыкмаганнардыр, алар безнең башта яшиләрдер кебек. Һәркемнең – үз тараканнары бит хәзер…



Рәис Габдулла

28 гыйнвар санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: робагый, он, сыерчык, киек, күчән, шама, Лувр, мәл, суер, анкер, дала, ашуг, нанай, Браун, Полонез, Ирина, гел. **Вертикаль буенча:** Майн, пин, үшән, Арбор, чалкан, Лия, Рөстәм, аргон, Насрый, Наг, боек, Анри, Леда, Разил, Чебурашка, ышык, Лу, арпаган.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 «Болгари» сүзе нәрсәне аңлата?

А) хәрби титул;
Б) гөмбәзсыман түбәле дүрт катлы бина;
В) юка гына итеп эшкәртелгән махсус сортлы күн.

2 «Хуш инде, мәңгегә
Хуш инде.
Китә яз, китә наз –
Кыш инде.
Тагын бер текәлеп
Карыймчы:
Рәсемеңне күңелемә
Алыймчы».
Бу шигырь юллары кемнеке?

А) Илдар Юзеев;
Б) Марсель Галиев;
В) Рәмис Аймәт.

3 «Антанта» хәрби блогы кайсы дәүләтләрне берләштергән?

А) Россия, Германия, Франция;
Б) Франция, АКШ, Япония;
В) Россия, Бөекбритания, Франция.

4 Борис Годуновның идарә иткән еллары.

А) 1598–1605;
Б) 1741–1761;
В) 1564–1572.

Җаваплар: 1) В; 2) А; 3) В; 4) А.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 216

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+